ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исем.
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**О. Н. Галимова, И. И. Сабитова,**
**Э. И. Сафина, Ф. И. Таһирова, Р. Т. Сәфәров**

# БАШ ХӘРЕФТӘНМЕ, ЮЛ ХӘРЕФЕННӘНМЕ?

## ОРФОГРАФИК СҮЗЛЕК

КАЗАН • 2022

**УДК 81′374.823**
**ББК 81.2Тат-4**
**Б 33**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

**Фәнни редактор**
филология фәннәре кандидаты **Р. Т. Сәфәров**

**Бәяләүчеләр:**
филология фәннәре кандидаты **Ә. К. Булатова**
филология фәннәре кандидаты **Р. Х. Мөхиярова**

Б 33 **Баш хәрефтәнме, юл хәрефеннәнме?: Орфографик сүзлек** / О. Н. Галимова, И. И. Сабитова, Э. И. Сафина, Ф. И. Таһирова, Р. Т. Сәфәров; фәнни ред. Р. Т. Сәфәров. — Казан: ТӘһСИ, 2022. — 240 б.
ISBN 978-5-93091-460-3

Сүзлек хәзерге орфографиянең катлаулы проблемаларыннан берсе — сүз башында баш хәреф яки юл хәрефе кулланылышына багышланган. Ул баш хәрефтән язылa торган берничә компонентлы шәхси исемнәрне, географик объектларның, тарихи чорларның атамаларын, дини төшенчәләрне һ.б.ны үз эченә ала; шулай ук сүзлеккә баш хәрефтән хаталы язылу ихтималы булган, ләкин фәкать юл хәрефеннән генә язылa торган сүзләр һәм сүзтезмәләр дә кертелгән. Моннан тыш, орфографик яктан беренче баш хәреф яки юл хәрефе белән генә аерыла торган сүзләр дә исәпкә алынган.

Сүзләр һәм сүзтезмәләр алфавит тәртибендә бирелгән, аларның басымнары күрсәтелгән һәм, кирәк булганда, кыскача аңлатмалар белән тәэмин ителгән.

Сүзлек укучылар, студентлар һәм укытучылар, әдәбиятчылар һәм нәшрият хезмәткәрләренә тәкъдим ителә.

УДК 81'374.823
ББК 81.2Тат-4

**ISBN 978-5-93091-460-3**

© Галимова О.Н., Сабитова И. И.,
Сафина Э. И., Таһирова Ф. И.,
Сәфәров Р. Т., 2022
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2022

## КЕРЕШ

Орфография — татар тел белеменең иң катлаулы тармакларыннан берсе. Ул турыдан-туры язуга кагыла, сөйләмнең грамматик формаларының һәм сүзләрнең бер үк төрле язылышын тәэмин итә. Язылышның бертөрлелеге исә әйтелешнең индивидуаль һәм диалекталь үзенчәлекләрен шомарта һәм үзара аңлашуны җиңеләйтә.

Баш хәрефләр кулланылышы татар язуында 1927 елда гарәп графикасыннан латин графикасына күчкәч кенә гамәлгә керә. Язу практикасы хәзерге вакытта орфографиядә баш хәрефләр кулланышының иң тотрыксыз өлкә булуын һәм тәртипкә салынып бетмәвен күрсәтә.

Бу күпмедер дәрәҗәдә баш хәрефләр кулланылышының чагыштырмача күптән түгел нормалаштырылуы белән, шулай ук соңгы 20—30 елда күп кенә төшенчәләрнең (мәсәлән, дини өлкәгә караганнарның) җәмәгатьчелек аңында яңаруы, идеологик ориентирларның үзгәрүе белән аңлатыла. Болар исә дәүләт учреждениеләре, иҗтимагый-сәяси оешмалар, бәйрәмнәр, орденнар һәм башка категорияләрдәге атамаларның исемнәрен язуга да тәэсир итә.

Татар теленең хәзерге орфографиясе 1941 елда Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы тарафыннан расланган «Татар әдәби теленең алфавиты һәм орфографиясе»[1] кагыйдәләр җыентыгына нигезләнә. Бу кагыйдәләр арасында «Баш хәреф орфографиясе» бүлеге дә бар. Шактый чикле күләмдәге әлеге кагыйдәләр баш хәрефләр кулланылышының нигезләрен генә чагылдыра алган. Х. Курбатов югарыда телгә алынган кагыйдәләр җыентыгындагы баш хәрефләр бүлеге детальләп бирелгән дип санаса да, «...культуралы телләрдә орфография кагыйдәләре җыентыгында

[1] Татар әдәби теленең алфавиты һәм орфографиясе. — Казан: Таткнигоиздат, 1941. — 23 б.

баш хәрефләр кулланылышы бүлеге чагыштырмача бик зур урын алып тора» дип ассызыклый[1].

Шул еллардан бирле баш хәрефләр кулланышына багышланган хезмәтләр мәктәп дәреслекләре белән чикләнә. Шуның белән бергә 1941 елгы җыентыктагы кайбер пунктлар бүген инде искергән дип бәяләнә ала.

Кулыгыздагы сүзлекне әзерләгәндә, 1941 елгы җыентыкның тәкъдимнәре яңадан күздән кичерелде, баш хәрефләрне куллану кагыйдәләре, бүгенге көн ихтыяҗларыннан чыгып, яңадан формалаштырылды, һәм кагыйдәләрнең бу яңа редакциясе әлеге сүзлектә чагылыш тапты.

Ниндидер сәбәптән сүзлеккә керми калган сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең, шулай ук яңа гына барлыкка килгән сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең баш хәрефтән яки юл хәрефеннән язылышы белән бәйле сорауларга җавапларны табуда түбәндә китерелгән «Баш хәрефтән язылу кагыйдәләре» ярдәм итәчәк (к. 11—38 б.).

Сүзлек мәктәп укучыларыннан һәм студентлардан алып укытучылар, журналистлар, нәшрият һәм редакция хезмәткәрләре кебек киң катлау укучыга атап төзелде.

## Лөгатьлек нәрсәдән гыйбарәт?

Бу сүзлекнең төп предметы — хәзерге орфографиядә баш хәрефтән яки юл хәрефеннән язылуы кыенлык тудыру ихтималы булган очраклар. Шуңа күрә бер генә сүздән гыйбарәт (кушылып языла торган) шәхси, географик яки башка ялгызлык исемнәр, кагыйдә буларак, сүзлеккә алынмады. Ялгызлык исемнәрдән сүзлеккә аерым, дефис аша яки бәйлекләр, артикльләр, кисәкчәләр кебек ярдәмче элементлары булган төрле структуралы төзелмәләр кертелде. Аларга, мәсәлән, түбәндәге берәмлекләр керә:

**Аксак Тимер, Кануни Сөләйман, Македонияле Искәндәр, Саровлы Серафим, Сәйфи-Казанлы; Васко да Гама, Конан Дойль, Ле Корбюзье, Леконт де-Лиль, Ортега-и-Гассет, Сент-Экзюпери, Һарун әр-Рәшид, Чайльд Гарольд, Эль Греко;**

[1] Курбатов Х. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. — 139 б. — Б. 131.

**Йошкар-Ола, Орехово-Зуево, Ростов-на-Дону, Санкт-Петербург, Түбән Новгород, Яр Чаллы; Булонь-сюр-Мер, Лас-Пальмас, Лос-Анджелес, Нью-Йорк, Па-де-Кале, Порт-Сәгыйд, Рио-Браво-дель-Норте, Санта-Крус.**

Шулай ук сүзлеккә уртаклык исем мәгънәсендә кулланыла ала торган ялгызлык (шәхси, әдәби, мифологик, географик) исемнәр дә кертелде, мәсәлән:

**Аполлон, Вандея, Гамлет, Гаргантюа, Золушка, Кассандра, Клондайк, Манилов, Мәккә, Митрофанушка, Мюнхаузен, Плюшкин, Ротшильд, Хиросима, Хуҗа Насретдин, Чернобыль, Ювенал.**

Сүзлеккә шулай ук бер яки берничә компоненттан гыйбарәт географик атамалар, күбесенчә кайбер рәсми булмаган территория исемнәре алынды, мәсәлән:

**Балтия, Вологодчина, Днестр Буе, Кавказ Арты, Оренбуржье, Орловщина, Идел Буе, Мәскәү Яны, Скандинавия, Ставрополье.**

Сүзләрнең бу төркемнәреннән тыш, сүзлектә мөстәкыйль сүзлек берәмлеге сыйфатында баш хәрефтән языла торган сүзләрнең һәм алар кулланылган сүзтезмәләренең түбәндәге категорияләре тәкъдим ителде:

— диндә изге дип саналган затларның, күренешләрнең һәм төшенчәләрнең исемнәре, мәсәлән:

**Алла(һ), Аллаһы Тәгалә, Библия, Инҗил, Коръән, Кыямәт көне, Өчберлек, Раббы, Тәүрат, Ханука;**

— тарихи чор атамалары:

**Кватроченто, Реформация, Рисорджименто, Проторенессанс;**

— тотрыклы тезмәләр составына кергән ялгызлык (шәхси, мифологик, географик) исемнәр, мәсәлән:

**Архимед законы, Бойль — Мариотт законы, Боткин авыруы, Гиппократ анты, икейөзле Янус, Калашников автоматы, Линч суды, Ньютон биномы;**

**Лаеш шулпасы эчмәгән, Мәнди анасы да белү, Рубиконны кичү, Сцилла белән Харибда арасында; Гриндвич буенча, Цельсий буенча, Рихтер шкаласы буенча;**

— составына уртаклык исемнәр (шул исәптән үзләренең туры мәгънәләрендә кулланылмаган сүзләр) кергән

кушма (парлы, тезмә) атамалар; атап әйткәндә болар эченә географик, астрономик исемнәр, тарихи затларның, мифологик һәм әдәби персонажларның исемнәре, тарихи чорларның һәм вакыйгаларның исемнәре, календарь чорлар һәм бәйрәмнәр, оешмалар һәм учреждениеләр, дәүләт берләшмәләре исемнәре кертелде, мәсәлән:

**Алтын Урда, Бәйсез Дәүләтләр Берлеге, Беренче бөтендөнья сугышы, Беренче май, Берләшкән Милләтләр Оешмасы, Бөек Пётр, Варфоломей төне, Генерал Сафиуллин урамы, Дәүләт думасы, Ерак Көнчыгыш, Илҗә көне, Иске Татар бистәсе, Кара диңгез, Киек Каз Юлы, Куликово сугышы, Мәңгелек шәһәр, Мәскәү елгасы, Олы ураза, Париж коммунасы, Россия Федерациясе, Тәре яулары, Труйчын көне, Урта гасырлар, Федераль собрание, Царское Село, Яңа ел.**

Сүзлеккә чикле дәрәҗәдә генә аббревиатуралар да кертелде. Ешрак кулланыла торган кыскартылмалар икешәр тапкыр бирелде: кыскартылма формасында (**АКШ, БМО**) һәм тулы килеш (**Берләшкән Милләтләр Оешмасы (БМО)**.

Сүзлеккә шулай ук аерым сүзлек мәкаләсе сыйфатында юл хәрефеннән генә языла торган кайбер сүзләр һәм сүзтезмәләр дә кертелде. Монда юл хәрефе урынына ялгыш баш хәрефтән язылу ихтималы булган төрле очраклар турында сүз бара, мәсәлән: **пушкиниана, лениниана** яки **сабитовчылык, солтангалиевче, щепкинчы** кебек ялгызлык исемнәрдән ясалган яңа исемнәр; **кавээнчы**, **мхатчы** тибындагы аббревиатурадан ясалган сүзләр; җитәкче вазифаларның исемнәре — **губернатор, министр, мэр, префект** һ. б.; төрле илләрнең парламентлары, геологик чорлар һәм периодлар исемнәре; берникадәр мифологик исемнәр, мәсәлән: **ганка, горгона, дию;** шулай ук **зодиак, җиһад, ка́рма** кебек аерым сүзләр, **ачык ишекләр көне, ял йорты, балалар йорты** кебек сүзтезмәләр һ. б.

Сүзлек тулылыкка дәгъва итми. *Бер типтагы сүзләрнең* (оешма, географик объектлар һ. б. ның исемнәре) *бер ишләре үрнәк буларак кына тәкъдим ителә.* Белешмәлекнең төп бурычы — бер типтагы атамаларның язылыш принципларын аерым мисалларда күрсәтү. Шуңа күрә, мәсәлән, сүзлектә

берничә компонентлы атамалардагы кабатлана торган **Бөтендөнья, Дәүләт, Татарстан, Казан, Көньяк, Көнчыгыш** һ. б. ш. типтагы сүзләрне шул ук компонентлы башка сүзләр язылышының характерын күрсәтә торган үрнәкләр буларак карарга кирәк.

Сүзлектә аерым роль нигез сүзләргә бирелә. Конкрет бу очракта нигез сүз дигәннән төрле составлы (бер сүзле булмаган) бер төркем атамаларда кулланыла һәм аерым шартларга бәйле рәвештә я баш хәрефтән, я юл хәрефеннән, я һәм баш хәрефтән, һәм юл хәрефеннән языла торган сүзләр күз уңында тотыла. Шулай ук рус телендә атаманың беренче сүзе булганда баш хәрефтән языла, татар телендә беренче сүз булмаганда юл хәрефеннән языла торган кайбер сүзләр дә нигез сүзләр рәтендә каралды. Аларга, мәсәлән, **академия, банк, җәмгыять, инспекция, комиссия, комитет, музей, оешма, партия, республика, союз, фонд** һ. б. сүзлек берәмлекләре керә. Мондый сүзләргә багышланган сүзлек мәкаләләре киңрәк характерда бирелә — аларда составларына нигез сүзләр кергән атамалардан төрле мисаллар китерелә.

* * *

Татар телендә Коръән сүрәләренең кулланылыш традициясе бик күптәннән килә. Гадәт буенча аларны тәрҗемә итмиләр, гарәпчә яңгырашларын саклыйлар. Шулай да сүрә исемнәрен язганда берникадәр төрлелек күзәтелә. Язудагы вариантлардан качу максаты белән, сүзлеккә сүрәләрнең ра́смән кабул ителгән һәм халык арасында таралган исемнәре дә кертелде. Сүрә исемнәренең язылышын унификацияләү өчен, түбәндәге принциплар нигез итеп алынды: а) ялгызлык исемнәр буларак, сүрә исемнәре баш хәрефтән языла; ә) сүрәләрнең исемнәре куштырнаклар эченә алына; б) сүрәләрнең гарәп телендә *әл-* билгелелек артикле белән кулланылган исемнәре татар телендә, кагыйдә буларак, артикльсез кулланыла; в) сүзлектә гарәпчә исем янына җәяләр эчендә татарча тәрҗемәләре дә бирелде. (Ягъни традицион гарәп формасы белән бергә яки аның урынына сүрәнең татарча тәрҗемәсеннән файдаланырга мөмкин, ләкин та-

тарча вариантлар үзләре мөстәкыйль сүзлек мәкаләсе итеп бирелмәде, мәс.: *«Бәкара» сүрәсе, «Сыер» сүрәсе*); г) сүрә исемнәренең татарчага транслитерациясе мөмкин кадәр гарәпчәләренә якын итеп башкарылды (шул ук вакытта фәндә күптән кабул ителгән кагыйдәләр дә истә тотылды, мәс.: әлиф хәрефе сүз уртасында һәм сүз ахырында «ә» яки «әә» формасында түгел, һәрвакыт «а» хәрефе аша бирелде, мәс.: «Нәс» яки «Нәәс» түгел, «Нас» сүрәсе); д) татар теленә кереп күптән үзләшкән шәхси исемнәрдән гыйбарәт сүрә исемнәренең гарәпчә яңгырашын саклау берникадәр ясалмалык китереп чыгарганлыктан, аларны татарча яңгыраштa бирү акылга ятышлырак дип табылды, мәсәлән: «Лукман» түгел, «Локман» сүрәсе, «Юсуф» түгел, «Йосыф» сүрәсе. Мәгәр татар телендә дә сүрә исемнәрен «Лукман», «Юсуф», «Юнус», «Мухәммәд» дип куллануны ялгыш дип санамыйбыз.

### Сүзлекнең структурасы турында

Сүзлектә китерелгән барлык берәмлекләр (сүзләр һәм сүзтезмәләр) алфавит тәртибендә бирелә.

Баш хәрефтән дә, юл хәрефеннән дә языла торган сүзләр сүзлектә ике орфографик вариантта да тиешле аңлатмалар белән бирелә. Мәсәлән:

**игезәклә́р**[1] (*бер анадан бер вакытта туган балалар*);
**игезәк** (*шуларның сыңары*)
**Игезәклә́р**[2] (*йолдызлык һәм зодиак билгесе, Җәүза*);
**Игезәк** (*шул йолдызлык астында туган кеше*)

**корольле́к**[1] (*дәүләтләрнең тар. исемнәрендә*), *мәс.*: Германия корольлеге, Сицилия корольлеге, Франция корольлеге, Италия корольлеге
**Корольле́к**[2] (*хәзерге дәүләтләрнең рәсми исемнәрендә*), *мәс.*: Иордания Һашими Корольлеге, Бельгия Корольлеге, Дания Корольлеге, Испания Корольлеге, Марокко Корольлеге…

Орфографик яктан беренче хәреф, баш хәреф яки юл хәрефе белән генә аерылып торган сүзләр яки сүзтезмәләр, мәсәлән, **төньяк** һәм **Төньяк**, **Геркулес** һәм **геркулес**, **союз** һәм **Союз**, **бөек** һәм **Бөек** (сүзтезмәләрдә бу сүз беренче дә,

икенче дә булырга мөмкин), төрле сүзлек мәкаләләрендә бирелә, ләкин төркемгә берләштерелә. Мондый төркемнәрнең һәрберсендә сүзлек мәкаләләре номерлана. Мисал:

**Геркуле́с**[1] (*мифол.; йолдызлык*)
**геркуле́с**[2] (*күч. бик көчле кеше*)
**геркуле́с**[3] (*ярма*)

**Сейше́ль утраулары́**[1] (*геогр.*)
**Сейше́ль Утраулары́**[2] (*дәүләт*)

Баш сүзләренең язылышлары бер үк булган төркемнәр дә шул ук рәвешле билгеләнә. Мисал:

**дива́н**[1] (*тар. Алтын Урда һәм татар ханлыкларында хөкүмәт*)
**дива́н**[2] (*иск. тупланма, җыентык*)
**дива́н**[3] (*өй җиһазы*)

**о́рден**[1] (*бүләк*), *мәс.:* Дуслык ордены (*Россиядә*), «Дуслык» ордены (*Татарстанда*), Кызыл Йолдыз ордены, Ленин ордены, Халыклар дуслыгы ордены, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены
**о́рден**[2] (*тарикать*), *мәс.:* госпитальерлар ордены, тамплиерлар ордены, Ливон ордены, Тевтон ордены, Мальта ордены

Сүзтезмә составындагы икенче яки беренчедән гайре сүз баш хәрефтән язылса, ул сүзлек мәкаләсенең баш сүзе итеп чыгарыла, ике ноктадан соң сүзтезмәдәге язылыш тулысынча китерелә. Мәсәлән:

**ге́рцоглык**[1] (*феодаль дәүләт*)
**Ге́рцоглык**[2]: **Бөе́к Люксембу́рг Ге́рцоглыгы** (*рәсми*)

**меду́за**[1] (*диңгез хайваны*)
**Меду́за**[2]: **горго́на Меду́за** (*мифол.*)

Объектның характерын күрсәтә торган аңлатмалар (җәяләр эчендә бирелде) географик объектлар (*шәһәр, посёлок, мәйдан, үткел, тау, күл* тибында), тарихи вакыйгалар (*тар.* тамгасы яки хронологик характердагы аңлатма), мифологик персонажлар һәм башка объектлар (*мифол.*

тамгасы яки конкретрак аңлатма), дини төшенчәләр (*дини, хрс.* тамгалары) һ. б. өлешчә куелды. Берничә сүздән гыйбарәт атамаларның уртаклык мәгънәсендә куллану ихтималы булганда, шулай ук аңлатмалар бирелде, мәсәлән: **Ак китап** (*документлар җыелмасы*), **Зур театр** (*Мәскәүдә*).

Бер үк объектның рәсми һәм рәсми булмаган атамаларын каршы кую әһәмиятле булган очракларда, сүзлектә *рәсми* һәм *рәсми түгел* тамгалары кулланыла, мәсәлән: **Тимирязев К. А. исемендәге Мәскәү авыл хуҗалыгы академиясе** (*рәсми*); **Тимирязев академиясе** (*рәсми түгел*); **Швейцария Конфедерациясе** (*дәүләт, рәсми*).

Кыскартылмалар, мөстәкыйль сүзлек мәкаләсе булганда, һәрвакыт ачылып аңлатылды, шулай ук аббревиатураларның дөрес әйтелешен һәм басымын күрсәтә торган транскрипцияләре дә бирелде, мәсәлән: **АЭС** (*кыск.:* атом электр станциясе); **КП**[1] [капэ́] (*кыск.: Коммунистлар партиясе*); **КП**[2] [капэ́] (*кыск.: команда пункты*).

Бөтен баш сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең басым билгеләре бирелде. Сүзтезмәләрдә басым һәр сүздә дә күрсәтелде. Бер иҗекле сүзләрнең басымы куелмады. Сүзлек мәкаләләрендә *мәс.* тамгасыннан соң иллюстратив материал буларак китерелгән сүзтезмәләрдә басымнар бирелмәде.

Сүзлек Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлегендә төзелде. Сүзлекнең авторлары: О. Н. Галимова (А—З хәрефләренә башлана торган сүзләр), И. И. Сабитова (И—Л), Э. И. Сафина (М—С), Ф. И. Таһирова (Т—Я). Кулъязма тулысынча бүлек мөдире Р. Т. Сәфәров тарафыннан редакцияләнде. Сүзлекнең кереш өлешләрен, баш хәрефтән язылу кагыйдәләрен Р. Т. Сәфәров әзерләде.

Сүзлекнең эшләнешенә, эчтәлегенә бәйле фикер һәм теләк-тәкъдимнәрегезне түбәндәге адреска юллый аласыз:

420111, Казан ш., К. Маркс ур., 12 нче йорт
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты.
Электрон адрес: iyali.anrt@mail.ru

# БАШ ХӘРЕФТӘН ЯЗЫЛУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

## Гомуми мәгълүмат

**1.** Баш хәреф ике функциядә кулланыла.

Беренчедән, ул текстның аерым өлешләренең башын билгеләп күрсәтү өчен хезмәт итә. Бу максат белән текстның беренче сүзе, шулай ук җөмләне тәмамлаучы нокта, күп нокталар, сорау һәм өндәү билгеләреннән соң килгән беренче сүз баш хәрефтән языла. Шигъри әсәрдә, гадәттә, һәр шигырь юлындагы беренче сүз шулай ук баш хәрефтән языла.

Икенчедән, баш хәреф текст төзелешенә бәйле булмаган аерым сүзләрне билгеләү өчен хезмәт итә. Алга таба баш хәрефнең икенче функциясендә кулланышын көйли торган кагыйдәләр каралачак.

Баш хәреф белән билгеләнгән сүзләр арасында: 1) тар мәгънәдә ялгызлык исемнәр һәм 2) атамалар аерыла.

Ялгызлык исемнәргә тар мәгънәдә кеше исемнәре, кушаматлары һәм хайван кушаматлары, географик һәм астрономик исемнәр керә. Атамаларга исә учреждениеләр, оешмалар, берләшмәләр, тарихи чорлар һәм вакыйгалар, бәйрәмнәр, массакүләм чаралар, орденнар, архитектура һәйкәлләре исемнәре, шулай ук куштырнаклар эченә алына торган газета, журнал, бүләк, сәнгать әсәрләре, җәмгыятьләр, предприятиеләр, сәнәгать эшләнмәләре һ. б. ның исемнәре керә.

**2.** Тексттагы сүзләрне баш хәреф ярдәмендә аеру ялгызлык исемнәрне уртаклык исемнәргә каршы кую өчен кулланыла: уртаклык исемнәр юл хәрефеннән языла, ялгызлык исемнәр — баш хәрефтән. Чаг., мәс.: *арыслан — Арыслан, йолдыз — Йолдыз, сәхнә — «Сәхнә» журналы.*

Ярдәмлек сүзләрдән һәм ыру төшенчәсен белдерә торган терминнардан тыш, ялгызлык исемнәр составындагы барлык сүзләр дә баш хәрефтән языла, мәс.: *Габдулла Тукай, Минтимер Шәрип улы Шәймиев, Кануни Сөләйман, Актәпи, Түбән Новгород, Чиләбе өлкәсе, Көнчыгыш Европа тигезлеге, Ирек мәйданы, Казык йолдыз.*

Берничә сүздән торган ялгызлык исемнәрдә баш хәрефтән беренче сүз генә языла (атама составына башка ялгызлык исемнәр кергән очраклардан тыш), мәс.: *Бөтендөнья профсоюзлар федерациясе, Мәскәү тарихы музее, Пётр чоры, Куликово сугышы, «Ватаным Татарстан» газетасы, «Сызгыра торган уклар» романы, «Хезмәт ветераны» медале.*

**3.** Ялгызлык исемнәр бериш предметларны гомумиләштереп билгеләү өчен дә кулланыла ала. Бу очракта алар ялгызлык категориясеннән уртаклык исем категориясенә күчә; мондый вакытта баш хәреф күп очракта юл хәрефе белән алыштырыла.

Шундый уртаклык исемнәргә күчеп, үлчәү берәмлекләренең исемнәре, галимнәр (*ампер, вольт, паскаль, рентген* һ. б.), шәхси исемнәр, фирма исемнәре, географик атамалар белән атала торган әйберләр, эшләнмәләрнең (*кием, корал, тукыма, эчемлек һ. б. төрләре*) исемнәре юл хәрефеннән языла, мәс.: *маккинтош, кольт, винчестер, бостон, бордо, хохлома, адидас;* ләкин: *Фаберже* (шул фирманың эшләнмәләре исеме буларак).

Тарихи шәхесләрнең, әдәби яки мифологик персонажларның ялгызлык исемнәре, ниндидер холык, характер билгеләре булган кеше исемнәре буларак гомумиләштереп (күчерелмә мәгънәдә) кулланылганда, бер үк төрле язылмый — бертөрлеләре юл хәрефеннән, икенчеләре баш хәрефтән. Күпчелек очракта аларның язылышлары куллаҥыш традициясе белән билгеләнә һәм сүзлек тәртибендә гамәлгә кертелә. Мәсәлән, *донкихот, донжуан, робинзон, иуда, меценат, геркулес, цербер, саламторхан, шомбай* сүзләре уртаклык мәгънәсендә кулланылганда юл хәрефеннән языла, *Гамлет, Обломов, Манилов, Плюшкин, Хлестаков, Аполлон, Цицерон, Наполеон* һәм башка кайбер исемнәр исә баш хәрефтән язылышларын саклый. Географик ата-

маларның гомумиләштереп (күчерелмә мәгънәдә) кулланылган очраклары да шул ук кагыйдәгә буйсына: мәс., *олимп* (танылган шәхесләрнең югары катламы), *камчатка* (*залда, сыйныфта арттагы рәтләр*) юл хәрефеннән языла, ләкин *Мәккә, Вандея, Клондайк, Хиросима, Чернобыль* һ. б. күчерелмә мәгънәләрдә баш хәрефтән язылышларын саклый.

## § 1. Кеше һәм мифологик затларның исемнәре, хайван кушаматлары

**1.** Исемнәр, фамилияләр, отчестволар, псевдонимнар, кушаматлар баш хәрефтән языла, мәс.: *Габдулла Тукай, Мөхәммәтшин Фәрит Хәйруллович, Чикерткә Гыйльменисасы, Зимагур Булат* (Ф. Бәйрәмова, «Кырык сырт»)*, Кече Мөхәммәд, Аксак Тимер, Сары Сәлим* (госманлы солтаны)*, Явыз Иван, Пётр Беренче (Пётр I), Арыслан Йөрәк Ричард*.

Шәхси исемнәрнең берничәсе турында сүз барганда яки алар күплек санда кулланылганда да, язылыш шул ук кагыйдәгә буйсына, мәс.: *бертуган Касыймовлар, морза Акчуриннар, ирле-хатынлы Габдрахмановлар, абыйлы-сеңелле Солтановлар; сыйныфтагы ике Кәрим дә бүген дәрестә юк.*

Династия исемнәре дә шулай ук баш хәрефтән языла, мәс.: *Әмәвиләр, Әюбиләр, Бөек Моголлар, Бурбоннар, Габбасилар, Габсбурглар, Газнәвиләр, Гәрәйләр, Госманлылар, Караханилар, Пәһләвиләр, Романовлар, Рюриклар, Сасанилар, Сәлҗукыйлар, Сәфәвиләр, Стюартлар, Тимериләр, Чыңгызилар, Шәйбанилар.*

**Искәрмә 1.** Кушамат беркайчан да куштырнаклар эченә алынмый: *Ни өчен Киев князе Святополкка Мәлгунь кушаматы тагылган?; Македонияле Искәндәр, Явыз Иван, Явыз Сәлим, Бөек Карл.*

Истә калдырыгыз:

| | |
|---|---|
| *Аксак Тимер* | *Арыслан Йөрәк Ричард* |
| *Акыллы Карл* | *Аучы Мәхмәт* |
| *Акылсыз Карл* | *Бөек Карл* |

*Бөек Людовик*
*Диндар Роберт*
*Елдырым Баязит*
*Җирсез Иоанн*
*Зур Оя Всеволод*
*Калта Иван*
*Канлы Мария*
*Канлы Николай*
*Кануни Сөләйман*
*Католик Фердинанд*
*Коручы Давид*
*Коштотар Һенрих*
*Македонияле Искәндәр яки Искәндәр Зөлкарнәйн*
*Матур Филипп*
*Сары Сәлим яки Сәрхуш Сәлим*
*Сукыр Василий*
*Явыз Иван яки Мөдһиш Иван*
*Явыз Сәлим*
*Якты Кояш Владимир*
*Ялган Дмитрий*

**Искәрмә 2.** Фамилиядәш яки адаш ике шәхесне аеру өчен фамилия яки исем алдыннан кулланыла торган *атасы, улы, өлкән, кече* кебек сүзләр, уртаклык исем булганлыктан һәм кушамат булып бетмәү сәбәпле, юл хәрефеннән языла, мәс.: *атасы Дюма, улы Дюма, өлкән Рокфеллер, кече Райкин.*

**2.** Тулы исемдә кемнеңдер атасының исеме белән килгән *улы (углы, оглы, оглу)* һәм *кызы* сүзләре юл хәрефеннән языла, мәс.: *Әмирхан Нигъмәтҗан улы Еникиев, Нигяр Худадад кызы Рәфибәйли, Күр углы.*

Шулай ук социаль хәлне, туганлык мөнәсәбәтләрен һ. б. ш. ны белдергән һәм ялгызлык исеменнән соң килгән *абый, ага, абзый, апа, бәй, бәк, би, җиңги, паша, хаҗи, хан, шаһ* һ. б. ш. сүзләр юл хәрефеннән языла, мәс.: *Шамил абый, Исмәгыйль бәк Гаспралы, Ямгырчы би, Әнвәр паша, Ибраһим хан.*

**Искәрмә.** Кайчандыр социаль хәлне яки иркәләп дәшүне белдереп, соңрак шәхси исем составына кереп киткән *шаһ, җан, хан, задә* һ. б. ш. сүзләр кушылып һәм юл хәрефеннән языла, мәс.: *Дәүләтша(һ), Таһирҗан, Тимерхан, Акъегетзадә*.

**3.** Иске татар телендәге исемнәр гарәпләрнең тулы исемнәре калыбында кулланылган (к. түбәндәгене).

1) Тулы гарәп исемнәрендә «атасы/анасы» мәгънәсендәге *әбү/үмм* (күнья) яки «улы/кызы» мәгънәсендәге *ибн/*

*бинт* (нәсәб) сүзләренә башланган гарәп һәм шулар калыбында язылган иске татар исемнәре һәрвакыт баш хәрефтән языла, мәс: *Ибн Халдун, Ибн Фадлан, Әбү Һүрәйрә, Бинт әш-Шати, Үмм Күлсүм.* Әгәр дә *ибн (бин) / бинт* сүзләре исемнең уртасында килсә, алар юл хәрефеннән языла, мәс.: *Мөхәммәд ибн Абдуллаһ, Хәдиҗә бинт Хүвәйлид.*

Гарәп һәм иске татар телләрендәге исемнәрнең ләкабь һәм нисбә өлешләрендәге *әл- (әт-, әд-, әр-, әз-, әс-, әш-, ән-)* артикле юл хәрефеннән һәм сызыкча аша языла, мәс.: *Әбү Муса әл-Әшгари, Шиһабетдин бин Баһаветдин әл-Мәрҗани, Әбү Гали Хөсәен ибн Габдуллаһ ибн әл-Хәсән ибн Гали ибн Сина, Һарун әр-Рәшид.*

**Искәрмә.** Гарәп теленнән алынган татар исемнәрендә, шулардан ясалган фамилияләр һәм отчестволарда *әбү (әбел), өмме (өмми), әл* компонентлары кушылып языла, мәс.: *Әбүзәр, Әбелхарис, Өммениса, Өммикамал, Әлфәрит*.

2) Әрмән фамилияләренең башында килгән *Тер-* өлеше һәрвакыт баш хәрефтән һәм сызыкча аша языла, мәс.: *Тер-Габриэлян, Тер-Петросян.*

3) Кореялы, вьетнамлы, бирмалы һәм индонезиялеләрнең, шулай ук японнарның шәхси фамилияләренең һәм исемнәренең һәр өлеше баш хәрефтән һәм аерым языла, мәс.: *Һо Ши Мин, У Ну, Ко Тун, Аунг Сан, У Ну Мунг, Такин Кодо Һмайн, Кураһара Корэһито.*

4) Япон исемнәрендәге хөрмәт белән эндәшкәндә кулланыла торган *-сан* (‘әфәнде’, ‘ханым’) компоненты юл хәрефеннән һәм сызыкча аша языла, мәс.: *Чио-Чио-сан, Мидзуки-сан, Тояма-сан*.

5) Кытай фамилияләре (алар һәрвакыт исемнәрдән алда килә) һәм исемнәре, иҗекләренең саны ничә булуга карамастан, кушылып һәм баш хәрефтән языла, мәс.: *Цяо* (фамилия) *Гуаньһуа* (исем), *Чэнь И, Сунь Ятсен.*

**4.** Европа һәм Көньяк Америка телләрендәге фамилияләрдә һәм исемнәрдә кулланыла торган артикльләр һәм кисәкчәләр юл хәрефеннән языла, мәс.: *д’Артуа, Леонардо да Винчи, фон дер Һольц, ла Мотт, Бодуэн де Куртенэ, Шарль де Голль, де ла Барт; Ортега-и-Гассет, Риего-и-Нуньес.*

Апостроф ярдәмендә кушыла торган *O’* һәм сызыкча аша кушыла торган *Мак-, Сан-, Сен-, Сент-* дип башланган фамилияләрнең барысы да баш хәрефтән языла, мәс.: *O’Коннор, Мак-Маһон, Сен-Симон, де Сен-Моран, Сан-Мартин.*

Сызыкча аша языла торган алынма *вига-, квази-, пан-, псевдо-* һ. б. ш. состав өлешләрдән соң ялгызлык исемнәр (кеше исемнәре һәм географик атамалар) баш хәрефтән языла: *анти-Франция, квази-Пушкин, пан-Европа, псевдо-Рафаэль, кино-Зөләйха* (‘кинода Зөләйха ролен уйнаган актриса’).

**Искәрмә 1.** Әгәр ярдәмлек сүзләр фамилияләр яки исемнәр белән берләшеп китсә, алар (кушылып яки дефис аша) баш хәрефтән языла, мәс.: *Лафонтен, Лавуазье, Ванкувер, Макдональд; Лас-Вегас, Лос-Анджелес*.

**Искәрмә 2.** Әгәр дә фамилия ярдәмлек сүздән башка кулланылмаса, ярдәмлекләр баш хәрефтән языла, мәс.: *Шарль Де Костер, Де Леон, Дос Пассос, Ле Телье.*

**Искәрмә 3.** Әгәр дә чыганак телдә ярдәмлек сүзләр баш хәрефтән язылса, татар телендә дә баш хәрефтән языла, мәс.: *Эдмундо Де Амичис, Ди Витторио*.

**Искәрмә 4.** Итальян, испан һәм португал исемнәре яки фамилияләре алдыннан килә торган ‘әфәнде’ яисә ‘ханым’ мәгънәсендәге *дон, донья, донна, дона* сүзләре аерым һәм юл хәрефеннән языла: *дон Базилио, дон Андреа.* Ләкин *Дон Кихот* һәм *Дон Жуан* әдәби персонажларының исемнәрендә ике өлеш тә баш хәрефтән языла. Уртаклык исемнәр булган *донкихот* һәм *донжуан* исә кушылып һәм юл хәрефеннән языла.

**Искәрмә 5.** Юл хәрефеннән языла торган артикльләр, җөмләнең беренче сүзе булып килгәндә, баш хәрефтән языла, мәс.: *Әл-Бохариның «Сахих»ы тәрҗемә ителә башлаган. Де ла Мотт Бранденбургта туган. Д’Артуа Англиягә китә.*

**5.** Дин һәм мифологиягә караган индивидуаль исемнәр баш хәрефтән языла: *Аллаһ, Иисус Христос (Гайсә Мәсих), Будда, Браһма, Зевс, Марс, Нептун, Иблис; Сән улгыл хәзрәте Хәттаб, бетер һәп потлары таптап, // Ки калсын Кәгъбәи пакь-пакь Мәнаттан, Лат вә Гоззадан* (Г. Тукай).

Дин һәм мифологиягә караган ыру атамалары[1] юл хәрефеннән языла: *фәрештә, җен, пәри, шайтан, гыйфрит, дию, аждаһа, шүрәле, валькирия, нимфа, сатир, сирена.* Берничә сүздән гыйбарәт ыру атамалары да шул ук кагыйдәгә буйсына, мәс.: *су анасы, йорт иясе, урман иясе, дию пәрие, убырлы карчык.*

**Искәрмә.** Дин белән бәйле булган башка исемнәр турында к. § 5.

**6.** Уртаклык исем булып киткән ялгызлык исемнәр юл хәрефеннән языла: *саламторхан, шомбай, карун, альфонс, донжуан, ловелас, меценат.*

Әгәр дә уртаклык исем мәгънәсендә кулланылган фамилия уртаклык исемнәр разрядына күчмәсә, аның баш хәрефтән язылышы саклана: *«Параллель җир»дә үз Тукайлары, үз Байроннары, Пушкиннары булган* (А. Тимергалин).

Кеше исеменнән яки фамилиясеннән ясалган уртаклык исемнәр — предмет, эшләнмә, кием-салым, корал, тукыма, үсемлек төрләренең, шулай ук үлчәү берәмлекләренең исемнәре юл хәрефеннән языла: *ампер, ватман, вольт, галифе, кулон, макинтош, наган, ом, ремингтон, рентген, сөләйман балыгы, френч, юныс балыгы.*

**7.** Хайван, кош-корт кушаматлары баш хәрефтән языла, мәс.: *Актырнак, Мыраужан, Мияубикә, Актәпи; Кызык инде: колхоз аты — Гөбәдия! Югыйсә әнә Заһри аты — Трактор,*

[1] Сүзләр үзләренең мәгънәләрендә тышкы дөнья объектлары арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдыра ала. Нинди дә булса предметларның, затларның, хайваннарның, гамәлләрнең, хәлләрнең, сыйфатларның һ. б. ш. ның билгеле бер классын атаган сүзләр белән шул класс эченә кергән объектларның, гамәлләрнең, сыйфатларның төрләрен атаган сүзләр арасындагы мөнәсәбәт ыру-төр мөнәсәбәтләре (яки гиперонимик-гипонимик мөнәсәбәт) дип атала. Мәсәлән, *агач* сүзе *каен, миләш, имән, өрәңге, чыршы, нарат* сүзләренә карата — ыру атамасы (гипероним), саналган агачларның исемнәре исә *агач* сүзенә карата — төр атамалары (гипонимнар). Шул ук вакытта *агач, куак, үлән* рәтендәге сүзләр өчен ыру атамасы (гипероним) буларак *үсемлек* сүзе кулланыла. Ягъни төрле позициядән караганда һәм гомумиләштерүче сүзнең булу-булмавын исәпкә алып, бер үк сүз берьюлы гипероним да, гипоним да була ала.

*Гыйнду аты — Әрмәс, Мәҗит абый аты — Эркәкә (РККА, ягъни Рабоче-крестьянская Красная армия) һ. б., һ. б.* (М. Мәһдиев); *Җәүһәрия Куштанбикә белән Кодагыйның әле берсен, әле икенчесен сыйпаштыра, иркәләп, мөгез араларын кашый иде* (Г. Бәширов).

**Искәрмә 1.** Әгәр индивидуаль исем хайван төренең атамасы буларак яки күчерелмә мәгънәдә кулланылса, ул юл хәрефеннән языла: *акбай; Үзең сарык булгач, көтүчең сарбай булганга үпкәләмә* (Мәкаль), *Имчәкләренең җиргә тияр-тимәс чайкалып баруыннан абайладым — һичшиксез, яшь көчекләре янына ашыга иде бу алабай (соңыннан белдем: исеме дә Алабай икән)* (Ф. Шәфигуллин). *Сабантуй көнне дә саварга кирәк ул сөтлебикәләрне* (Т. Нәҗмиев).

**Искәрмә 2.** Хайван токымнарының исемнәре юл хәрефеннән языла, мәс.: *пудель, сенбернар — этләр, ахалтәкә, битюг — атлар; Акча кызганып тормадык, утыз баш холмогор тана алып кайттык, буазларны* (Х. Хәйруллин). Токым составына кергән ялгызлык исемнәр баш хәрефтән языла, мәс.: *Бестужев токымлы сыер, Оренбург кәҗәсе, Орлов тавык токымы, Орлов юртагы, Бельгия мастифы, Андалусия аты.* Рус теленә, кагыйдә буларак, мондый ялгызлык исемнәре юл хәрефеннән языла торган сыйфат буларак тәрҗемә ителә: *бестужевская порода коров, оренбургская коза, орловский рыскак, бельгийский мастиф* һ. б.

**8.** Мәсәл, әкият, пьеса кебек кайбер әдәби әсәрләрдә асылы уртаклык исеме булган персонаж исемнәре, ялгызлык исемгә әйләнеп, баш хәрефтән языла: *Төлке, Бүре, Куян* (М. Гафуриның «Сарыкны кем ашаган?» мәсәле геройлары), *Аккош, Чуртан һәм Кысла* (И. Крыловның шундый ук исемле мәсәле геройлары); *Әтәч, Дөя, Төлке* (төрле әкият персонажлары).

**Искәрмә 1.** Персонаж исемен тәшкил иткән компонентлар бергә килгәндә генә шул персонажның исеме оешса, компонентларларның һәрберсе баш хәрефтән языла, мәс.: *Ак Бүре, Ак Елан, Дию Пәрие, Зәңгәр Сакал, Кар Кызы, Кызыл Калфак, Кыш Бабай, Су Анасы.*

**Искәрмә 2.** Персонажның ялгызлык исеме янәшәсендә килә һәм төшереп калдырыла ала торган уртаклык

исемнәре юл хәрефеннән языла, мәс.: *Мазай бабай, Дадон патша, барон Мюнхаузен,* компонентлар *леди Макбет, доктор Айболит, крокодил Гена* (ләкин: *Хуҗа Насретдин*).

**9.** Татар телендә шәхси исемнәрдән сыйфатлар ясалмый. Рус телендә исә шәхси исемнәрдән сыйфатлар ясала ала, һәм рус теле кагыйдәләре нигезендә алар кайбер очракта баш хәрефтән, кайбер очракта юл хәрефеннән языла. Мондый сүзләрне тәрҗемә иткәндә татар телендә дөрес язу өчен, һәр очракка чагыштырма планда тукталырга кирәк.

Рус телендә шәхси исемнәрдән, фамилияләрдән, кушаматлардан *-ов (-ев)* яки *-ин* кушымчасы ярдәмендә ясалган һәм иялек мөнәсәбәтен белдергән сыйфатлар баш хәрефтән языла, мәс.: *Рафаэлева мадонна, Шекспировы трагедии, Гегелева «Логика», Далев словарь, Иваново детство, Танина книга, Муркины котята*. Татар теленә мондый сүтезмәләр изафә конструкциясе белән тәрҗемә ителә, исемнәр, фамилияләр, кушаматлар баш хәрефтән языла, мәс.: *Рафаэль мадоннасы, Шекспир трагедияләре, Гегельнең «Логика»сы, Даль сүзлеге, Иванның балачагы, Таняның китабы, Мурканың балалары*.

Шул ук вакытта фразеологик берәмлекләр һәм берничә сүздән торган терминнар составында *-ов (-ев)* яки *-ин* кушымчасы ярдәмендә ясалган сыйфатлар рус телендә юл хәрефеннән языла, мәс.: *авгиевы конюшни, ахиллесова пята, прокрустово ложе, сизифов труд, гордиев узел, драконовы законы, пиррова победа; вольтова дуга, бикфордов шнур, базедова болезнь, рентгеновы лучи*. Татар телендә кулланылганда исә рус телендәге сыйфатлар исем булып тәрҗемә ителә һәм баш хәрефтән языла, мәс.: *Авгий абзарлары, Ахиллес үкчәсе, Прокруст ятагы, Сизиф эше (ташы), Гордий төене, Дракон законнары, Пирр җиңүе; Вольта дугасы, Бикфорд шнуры, Базедов авыруы, Рентген нурлары.*

**Искәрмә.** Татар теленең фразеологизмнары составына кергән ялгызлык исемнәр баш хәрефтән языла, мәс.: *моны гына Мәнди анасы да белә, Лаеш шулпасы эчмәгән.*

**10.** Шулай ук рус телендә исемнәрдән, фамилияләрдән, кушаматлардан *-ск-* кушымчасы ярдәмендә ясалган

сыйфатлар да юл хәрефеннән языла, мәс.: *далевский словарь, дарвиновское учение, бетховенская соната, шекспировские трагедии, пришвинская проза, суворовские традиции*. Ләкин әгәр дә мондый юл белән ясалган сыйфатлар берничә сүздән торган исем составында килсә, шул исәптән «фәлән исемендәге», «фәлән хөрмәтенә» мәгънәсендә булса, алар баш хәрефтән языла, мәс.: *Петровские реформы, Строгановское училище, Нобелевская премия, Ломоносовские чтения, Булгаковская конференция, Вахтанговский театр*.

Татар теленә мондый сүзтезмәләр изафә конструкциясе белән тәрҗемә ителә, һәр очракта да исемнәр, фамилияләр, кушаматлар баш хәрефтән языла, мәс.: *Даль сүзлеге, Дарвин тәгълиматы, Бетховен сонатасы, Шекспир трагедиясе, Пришвин прозасы, Суворов традицияләре; Пётр реформалары, Строганов училищесы, Нобель премиясе, Ломоносов укулары, Булгаков конференциясе, Вахтангов театры*.

**11.** Шәхси исемнәрдән һәм фамилияләрдән кушымчалар ярдәмендә ясалган һәм исемнәр белән изафәле бәйләнештә булмаган сыйфатлар юл хәрефеннән языла, мәс.: *ленинчыл, сталинчыл, марксистик*.

**12.** Рус телендә исем, фамилия, кушаматлардан ясалган рәвешләр юл хәрефеннән языла, мәс.: *по-таниному, по-петиному, по-пушкински, по-стахановски*. Татар телендә исә ялгызлык исемнәрдән ясалган рәвешләр баш хәрефтән языла, мәс.: *Таняча, Петяча, Пушкинча, Стахановча*.

**13.** Шәхси исемнәрдән һәм фамилияләрдән ясалган уртаклык исемнәр юл хәрефеннән языла, мәс.: *ленинчы, ленинизм, лениниана, дарвинизм, шопениана, толстойчылык, фәйзрахманчы, обломовчылык, солтангалиевче, стахановчы, стахановчылык*.

## § 2. Географик һәм административ-территориаль исемнәр һәм алардан ясалган сүзләр

**1.** Географик һәм административ-территориаль исемнәрдә — материк, диңгез, күл, елга, тау, ил, өлкә, торак пункт, урам һ. б. ш. исемнәрендә — *утрау, диңгез, тау, өлкә, провинция, урам, мәйдан, яр буе* кебек ыру атамаларыннан, ярдәм-

лек сүзләрдән, *ел* (*еллыгы*) сүзеннән тыш, барлык сүзләр дә баш хәрефтән языла. Мисаллар:

*Арктика, Азия, Европа, Финляндия, Кавказ, Кырым, Байкал, Урал, Яңа Зеландия, Төньяк Америка, Үзәк Азия; Көньяк полюс (котып), Төньяк ярымшар;*

*Идел, Сырдәрья, Везувий, Зур Баһама банкасы, Кече Баһама банкасы, Кивач шарлавыгы, Тамашлык үзәне, Төньяк Энгильчек бозлыгы, Днепр лиманы, Өмет борыны, Әрмән таулыгы, Онега күле, Төньяк Боз океаны, Ак диңгез, Яңа Җир утраулары, Устюрт платосы, Таймыр ярымутравы, Зур Ком чүле, Зәңгәр Нил, Мәскәү елгасы, Көнбатыш Җилләр агымы, Кысла тропигы, Фәннәр Академиясе сырты, Баш Кавказ сырты;*

*Краснодар крае, Орёл өлкәсе, Күгәрчен районы, Суссекс графлыгы, Көньяк Каролина штаты, Колумбия округы, Хоккайдо префектурасы, Сычуань провинциясе, Люблин воеводалыгы, Түбән Новгород, Киев, Париж, Новосибирск;*

*Галимҗан Ибраһимов проспекты, Мәскәү проспекты; 1 Май мәйданы, Горький паркы мәйданы, Ирек мәйданы, Азатлык мәйданы, Г. Камал исемендәге театр мәйданы; Кремль яр буе, Габдулла Тукай яр буе; Горький шоссесы; Пушкин бульвары; Дуслык тыкрыгы, Литвинов тыкрыгы; Болак күпере, Миллениум күпере, Красная Горка күпере; Генерал Мәхмүт Гәрәев урамы, Профессор Нужин урамы, Космонавтлар урамы, Центральная урамы, Октябрьнең 40 еллыгы урамы.*

Дефис аша языла торган географик атамалар составындагы компонентлар баш хәрефтән языла, мәс.: *Һинд-Ганг тигезлеге, Идел-Дон каналы, Ара-Хайгай аймагы, Сен-Готард үткеле (һәм туннеле), Баден-Вюртемберг җире, Сердце-Камень борыны, Новгород-Северский, Усть-Илимск, Садовая-Сухаревская урамы.*

**Искәрмә 1.** Рус телендә *Северо- (Северно-), Юго- (Южно-), Восточно-, Западно-* һәм *Центрально-* дип башлана торган географик атамалар парлы сүз итеп оештырыла (сызыкча аша), һәм аларның ике компоненты да баш хәрефтән языла, мәс.: *Северо-Байкальское нагорье, Северо-Кавказский федеральный округ, Восточно-Китайское море, Западно-Сибирская равнина, Центрально-Черноземный регион.* Татар телендә югарыдагы сүзләр

кергән географик атамаларның ике компоненты да шулай ук баш хәрефтән, ләкин аерым (сызыкчасыз) языла, мәс.: *Төньяк Байкал таулыгы, Төньяк Кавказ федераль округы, Көнчыгыш Кытай диңгезе, Көнбатыш Себер тигезлеге, Үзәк Черноземье регионы.*

**Искәрмә 2.** Географик атамалар составына кергән уртаклык исемнәр, үз мәгънәләрендә кулланылмаса, баш хәрефтән языла, мәс.: *Утлы Җир* (архипелаг), *Алтын Мөгез* (бухта), *Чех Урманы* (таулар), *Яшел Үзән* (шәһәр), *Зур Бассейн* (таулык), *Алтын Капка* (бугаз), *Елисей Кырлары* (Париждагы урам); *Кызыл Маяк, Балык Бистәсе, Зирекле Елга, Зур Алан, Иске Мунча* (Татарстандагы авыллар).

**Искәрмә 3.** Географик атаманың башында килгән ярдәмлек сүзләр (артикльләр, кисәкчәләр, бәйлекләр) баш хәрефтән языла, мәс.: *Лос-Анджелес, Ла-Манш, Лас-Вегас, Ле-Крезо, Де-Лонг, Әр-Рияд*. Атамалардагы беренче *Сан-, Сен-, Сент-, Санкт-, Санта-* кебек элементлар да шулай ук языла, мәс.: *Сан-Диего, Сен-Дени, Сент-Луис, Санта-Барбара, Санкт-Петербург* (шәһәрләр). Әмма ярдәмлек сүзләр географик атаманың уртасында булса, алар юл хәрефеннән языла, мәс.: *Ростов-на-Дону, Комсомольск-на-Амуре, Экс-ан-Прованс, Стратфорд-апон-Эйвон, Рио-де-Жанейро, Шуази-ле-Руа, Абруццо-э-Молизе, Булонь-сюр-Мер, Дар-әс-Сәлам, Баб-әл-Мәндаб.*

**Искәрмә 4.** Елга агымының өлешләрен белдерә торган сүзләр, әгәр дә атама составына кермәсә, юл хәрефеннән языла, мәс.: *югары Кама, урта Идел, түбән Урал*, ләкин: *Югары Ангара, Түбән Тунгуска* (елга исемнәре).

**2.** Дәүләтләрнең һәм дәүләт берләшмәләренең рәсми атамаларында, ярдәмлек сүзләрдән тыш, барлык сүзләр дә баш хәрефтән языла, мәс.: *Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе, Корея Халык Демократик Республикасы, Америка Кушма Штатлары, Мексика Кушма Штатлары, Бөекбритания һәм Төньяк Ирландия Берләшкән Корольлеге, Франция Республикасы, Көньяк Африка Республикасы, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Бәйсез Дәүләтләр Берлеге, Либия Гарәп Җамаһириясе.*

**3.** Дәүләт һәм континент өлешләренең терминологик характерда булган рәсми исемнәре баш хәрефтән язылa: *Европа Россиясе, Көнбатыш Белоруссия, Уңъяр Украина, Эчке Монголия, Азия Төркиясе, Төньяк Италия, Урта Азия, Үзәк Америка, Көньяк-Көнчыгыш Азия.*

**4.** Территориаль исем функциясендә яки шундый исем составына кергән дөнья тарафлары исемнәре баш хәрефтән языла, мәс.: *Көнбатыш илләре, Төньякны үзләштерү, Көнчыгыш халыклары, Ерак Көнчыгыш, Якын Көнчыгыш, Мәшрикъ, Мәгъриб, Ерак Төньяк* (рус. *Крайний Север*)*, Төньяк белән Көньяк сугышы* (АКШ тарихында)*, Төньяк-Көнбатыш* (Россия төбәге)*, Көньяк-Көнбатыш* (Мәскәү районы).

Дөнья тарафлары пространстводагы юнәлешләр буларак юл хәрефеннән языла: *көньяк, төньяк, көнчыгыш, көнбатыш, көньяк-көнчыгыш, төньяк-көнбатыш; Алды белән көньякка караган, уртасыннан төньяккарак кереп бөгелеп торган һәм шул рәвешчә дуга кебек булып күренгән бер зур тау итәгендә Миңгали карт бакчасы җәелеп ята иде* (Н. Фәттах).

**5.** Территория, өлкә яки төбәкләрнең бер сүз булып языла торган һәм башлыча рәсми булмаган исемнәре баш хәрефтән языла, мәс.: *Оренбуржье, Ставрополье, Брянщина, Орловщина, Вологодчина, Балтия, Скандинавия.* Шундый ук атамаларның берничә сүздән оешкан исемнәрендә *буе, аръягы, алды, арты* кебек сүзләр дә, географик атама да баш хәрефтән языла, мәс.: *Идел Буе, Идел Аръягы, Байкал Аръягы, Кама Аръягы, Кавказ Арты, Кавказ Алды, Кара Диңгез Буе, Днестр Буе, Амур Буе, Урал Алды; Казан Арты, Тау Ягы.* Ләкин *буе, аръягы, алды, арты* сүзләре, географик территорияне белдермәгәндә, юл хәрефеннән язылалар, мәс.: *Идел буе каеннары, авылның тау ягы.*

**6.** Дәүләтләрнең һәм шәһәрләрнең образлы исемнәрендә беренче сүз (ул берүзе генә дә була ала) һәм (булса) ялгызлык исемнәр баш хәрефтән языла, мәс.: *Кояш чыгу иле* (Япония), *Иртәнге сафлык иле* (Корея), *Ирек утравы* (Куба), *Күк асты иле* (Кытай), *Томанлы Альбион* (Англия), *Мең күл иле* (Финляндия), *Өрәңге яфрагы иле* (Канада), *Лаләләр*

*иле* (Голландия), *Мәңгелек шәһәр* (Рим), *Төньяк Пальмира* (С.-Петербург).

**7.** Тимерьюл станцияләре, вокзал, аэропорт исемнәрендә, ыру төшенчәләрен белдергән сүзләрдән тыш, барлык сүзләр дә баш хәрефтән языла, мәс.: *Санкт-Петербург, Юдино станциясе, Дәрвишләр бистәсе станциясе; Казан вокзалы* (Мәскәүдә)*, Шереметьево аэропорты, Внуково аэропорты.*

Метро станцияләре, җир өсте транспортының тукталыш исемнәре куштырнаклар эченә алына[1]. Аларның исемнәрендә беренче (яки бердәнбер) сүз баш хәрефтән языла; станция яки тукталыш исемендә кулланылган топоним составында баш хәрефтән язылган сүзләр шулай ук баш хәрефтән языла, мәс.: *«Яшьлек», «Җиңү проспекты», «Горки», «Әмәт», «Сукно бистәсе», «Кремль», «Авиатөзелеш», «Төньяк вокзал»* метро станцияләре; *«Мәктәп», «Космонавтлар урамы», «Балалар поликлиникасы»* тукталышлары.

**8.** Географик атамалардан ясалган уртаклык исемнәр — тукыма һәм башка әйберләр, эчемлекләр, хайван токымнары һ. б. ның исемнәре юл хәрефеннән языла, мәс.: *кашемир, бостон, джерси* (тукымалар), *хохлома, гжель* (бизәү ысулы), *бордо, цинандали* (шәраблар), *нарзан, боржоми* (минераль сулар), *ньюфаундленд* (эт токымы), *йоркшир* (дуңгыз токымы).

Географик атамалардан ясалган диалект, сөйләш, урынчылык исемнәре юл хәрефеннән языла, мәс.: *себер диалекты; урта диалектның әстерхан, балтач, бәрәңге, дөбьяз, лаеш, пермь сөйләшләре; минзәлә сөйләшенең әгерҗе, яңавыл, бәләбәй урынчылыклары; вологда һәм кострома сөйләшләре рус теленең төньяк диалектына кер*ә.

Калган очракларда уртаклык (күчерелмә) мәгънәдә кулланыла торган географик атамаларны юл хәрефеннән язу традиция белән билгеләнә һәм сүзлекләрдә теркәлгәнчә кулланыла (к. § 1, п. 2).

**9.** Географик атамалардан ясалган яшәүчеләр исеме (катойконимнар) юл хәрефеннән языла, мәс.: *казанлылар,*

[1] Куштырнаклар куллану территориаль берәмлекләрне метро станцияләреннән аеру өчен таләп ителә, мәс., Җиңү поспекты — «Җиңү проспекты» метро станциясе.

*мәскәүле кунак.* Сөйләм телендә шул ук мәгънәдә күплек санда кулланылган географик атамалар да юл хәрефеннән языла, мәс.: *делегация составында арчалар, балтачлар, уфалар да бар иде*.

Рус телендә географик атамалардан ясалган сыйфатлар юл хәрефеннән языла. Әгәр дә андый сыйфатлар берничә сүздән торган географик яки административ-территориаль атамалар, кеше исемнәренең нисбәләре, тарихи вакыйга, оешма, һәйкәл һ. б. ш. ның исемнәре составында килсәләр, баш хәрефтән язылалар, мәс.: *московские улицы, кварталы* һәм *Московская область, Московский вокзал* (С.-Петербургта)*, Московская государственная консерватория; казанские достопримечательности* һәм *Казанский кремль, Казанский университет, Казанский собор* (С.-Петербургта, Мәскәүдә). Татар теленә мондый сүзтезмәләр изафә конструкциясе белән тәрҗемә ителә, һәр очракта географик атамалар баш хәрефтән языла, мәс.: *Мәскәү урамнары, кварталлары* һәм *Мәскәү өлкәсе, Мәскәү вокзалы* (С.-Петербургта)*, Мәскәү дәүләт консерваториясе; Казанның истәлекле урыннары* һәм *Казан кремле* (Урта гасырлар корылмасы буларак)*, Казан университеты, Казан соборы* (С.-Петербургта, Мәскәүдә).

Географик атамалардан ясалган башка сыйфатлар да татар телендә баш хәрефтән языла, мәс.: *Питерча шавырма, Мәскәүчә яшәү рәвеше.*

Рус телендә географик атамалардан ясалган рәвешләр — юл (*танцевать по-московски*), татар телендә исә баш хәрефтән языла, мәс.: *Казанча биергә.*

## § 3. Астрономия атамалары

**1.** Күк җисемнәре, йолдызлыклар һәм галактикалар исемнәренең, *йолдыз, комета, йолдызлык, планета, астероид* һ. б. ш. ыру атамаларыннан һәм *альфа, бета, гамма* һ. б. грек алфавиты хәрефләре белән билгеләнгән тәртип билгеләреннән тыш, барлык сүзләре дә баш хәрефтән языла, мәс.: *Марс, Сатурн, Галактика* (безнең Кояш системасы да кергәне; ләкин: *ерак галактикалар*)*, Персеидлар, Җидегән йолдыз, Эрцгерцог Карл йолдызы, Киек Каз Юлы, Чаян, Зур Эт йолдызлыклары, Көньяк Балыкның альфасы, Андромеда*

*томанлыгы, Зур Магеллан Болыты галактикасы, Үгез Көтүчесе, Вероника Чәче йолдызлыклары; Сукояр, Укчы, Кәҗәмөгез* (йолдызлыклар һәм зодиак билгеләре); *Кояш, Җир, Ай*. Күк җисемнәрендәге аерым урыннарның исемнәре баш хәрефтән языла, мәс.: *Яз Күле, Салават Күпере Култыгы, Давыллар Океаны* (Айда), *Исида Тигезлеге* (Марста).

**Искәрмә.** *Кояш, җир, ай* сүзләре, астрономия термины булмаганда, юл хәрефеннән языла: *кояш баю, җиргә утыру, җир сөрү, җир өсте* (ландшафт булганда), *җир йөзе* (шулай ук *күк йөзе*), *ай яктысы* (чаг.: *Кояшның эчке төзелеше, Кояштагы таплар, Җирнең килеп чыгышы турындагы теорияләр, Җир кабыгы, Җир ресурсларын өйрәнү, Ай ландшафты, Айның арткы ягы*).

## § 4. Тарихи чорлар һәм вакыйгалар, календарь периодлар һәм бәйрәмнәр, чараларның исемнәре

**1.** Тарихи чорлар һәм вакыйгалар, календарь периодлар һәм бәйрәмнәр исемнәрендә исем составына кергән беренче сүз (ул бердәнбер булырга да мөмкин) һәм ялгызлык исемнәр баш хәрефтән языла, мәс.: *Урта гасырлар, Тәре яулары, Пётр чоры, Яңарыш* (шулай ук *Иртә Яңарыш, Югары Яңарыш*), *Ренессанс, Проторенессанс, Реформация, Кватроченто, Болганчык заман* (Россиядә XVII гасырда), *Варфоломей төне, Бородино сугышы, Куликово сугышы, Җидееллык сугыш, Беренче бөтендөнья сугышы, Гражданнар сугышы* (Россиядә 1918—1921 елларда); *Июль монархиясе, Икенче империя, Өченче республика* (Франция тарихында), *Париж коммунасы, Бәйсезлек өчен сугыш* (Төньяк Америкада), *Декабрь коралллы восстаниесе, Февраль революциясе (Февраль), Октябрь революциясе (Октябрь), Жакерия, Бакыр бунты, Тоз бунты, Яңа ел, Беренче май, Халыкара хатын-кызлар көне, Бәйсезлек көне, Укытучылар көне, Славян язуы һәм мәдәнияте көннәре, Елан елы, Үгез елы.*

Гомумдәүләт яки халыкара әһәмияткә ия булган сәяси, мәдәни, спорт һәм башка чараларның исемнәре дә шулай ук баш хәрефтән языла, мәс.: *Бөтендөнья икътисад форумы, Тынычлык маршы, Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар*

*фестивале, II Халыкара музыка фестивале, Олимпия уеннары, Футбол буенча дөнья кубогы, Дэвис кубогы, Ак олимпиада.* Регуляр үткәрелә торган башка чараларның исемнәре юл хәрефеннән язылa, мәс.: *донор көне, ачык ишекләр көне, матәм көне, туган көн.*

**Искәрмә 1.** Кайбер бәйрәмнәрнең һәм тарихи вакыйгаларның атамаларында традиция буенча беренче сүздән башкалар да баш хәрефтән языла, мәс.: *Бөек Ватан сугышы.*

**Искәрмә 2.** Цифр белән башланып киткән бәйрәм исемнәрендә ай исеме баш хәрефтән языла, мәс.: *1 Май, 8 Март, 23 Февраль.*

**Искәрмә 3.** Кабатлана торган фестиваль, конкурс, конференция, съезд, корылтай, сессия, конгресс кебекләрнең исемнәрендә тәртип саны цифр белән бирелсә дә, сүз белән билгеләнсә дә, шул саннан соң килгән сүз баш хәрефтән языла; исем составында кулланылган *фестиваль, конкурс, конференция, съезд, корылтай, сессия, конгресс,* шулай ук *халыкара, бөтенроссия, төбәкара* кебек сүзләр (цифр яки сүз белән бирелгән тәртип саныннан соң килмәсә) юл хәрефеннән языла, мәс.: *VI (Алтынчы) Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивале, I (Беренче) Чайковский исемендәге халыкара конкурс, XIV (Ундүртенче) «Державин укулары» халыкара фәнни-гамәли конференциясе, V (Бишенче) СССР халык депутатлары съезды, VI (Алтынчы) Бөтендөнья татар конгрессы корылтае*[1].

**Искәрмә 4.** Геологик эралар һәм чорлар, археологик дәверләр һәм культураларның исемнәре юл хәрефеннән языла, мәс.: *мезозой эрасы, акбур чоры, юра чоры, боз чоры, палеолит дәвере, таш гасыры, курган культурасы.* Шул ук вакытта исем составына ялгызлык исемнәр (башлыча

[1] Тәртип саны белән белдерелә торган чара исемнәренең бирелешендә нигез итеп алынган бер принцип юк. Аларның кайберләрендә тәртип саны беренче урында килә, кайберләрендә — уртада. Мәсәлән: V (Бишенче) СССР халык депутатлары съезды һәм СССР халык депутатларының бишенче съезды; VI (Алтынчы) Бөтендөнья татар конгрессы корылтае һәм Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтае.

торак пункт исемнәре) керсә, алар баш хәрефтән языла, мәс.: *Чиялек культурасы, Имәнкискә культурасы, Дьяково культурасы, Днепр-Донецк культурасы, Городец культурасы, Идел-Чулман культурасы, Триполье культурасы.*

## § 5. Дин белән бәйле атамалар

**1.** Монотеистик диннәрдәге иң югары илаһи зат буларак *Аллаһ* һәм шул ук мәгънәдә кулланылган *Алла, Хода(й), Тәңре* сүзләре баш хәрефтән языла. Мәҗүси илаһларның, пәйгамбәрләрнең, әүлияларның исемнәре дә баш хәрефтән языла, мәс.: *Яһвә, Шива, Браһма, Вишну, Умай, Перун, Зевс, Молох, Осирис, Ра, Астарта, Аврора, Вакх, Дионис, Мөхәммәд, Сөләйман, Будда, Зәрдөшт, Чукындыручы Иоанн, Кәрамәтче Николай.*

**Искәрмә.** «Бердәнбер яратучы» мәгънәсендә кулланыла торган *Алла(һ)* сүзен күпсанлы илаһи затларның берсен белдерә торган сүзләр урынына кулланырга киңәш ителми. Мондый илаһи затларны белдерү өчен, юл хәрефеннән языла торган *илаһ* һәм *алиһә* яки *илаһә* сүзләре урынлырак, мәс.: *Олимп илаһлары, Аполлон илаһ, сугыш илаһы, мәхәббәт алиһәсе.*

**2.** *Алла(һ)* сүзе урынына кулланыла торган бөтен сүзләр дә баш хәрефтән языла, мәс.: *Раббы, Илаһ, Рахман, Коткаручы; Изгелек эшлә дә суга ат, халык белмәсә, балык белер, балык белмәсә, Халикъ белер* (Мәкаль). *«Биргәнеңә шөкер, и Раббым», — дип, үзалдына сөйләнеп алды* (А. Әхмәтгалиева). *Менә ул [Ягъкуб] улларына: «Миннән соң нәрсәгә табыначаксыз?» — диде, алар исә: «Синең илаһыңа һәм бабаларың Ибраһим, Исмәгыйль һәм Исхакның илаһы булган бер Илаһка гыйбадәт кылачакбыз», — дигәннәр иде.*

Христианнарда өч чагылышлы бердәнбер илаһи зат мәгънәсендәге *Өчберлек*, шулай ук *Изге Өчберлек* һәм шуның йөзләрен тәшкил иткән *Алла Ата, Алла Ул (Угыл), Алла Изге Рух* сүзләрен баш хәрефтән язу киңәш ителә.

**Искәрмә 1.** Дини эчтәлекле текстларда (догаларда, вәгазьләрдә) *Алла(һ)* сүзе урынына кулланыла торган алмашлыклар баш хәрефтән кулланыла, мәс.: *(И Раббы-*

*быз!) Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз.*

*Күктәге Атабыз! Исемең изге дип икърар ителсен; Синең Патшалыгың килсен; күктәге кебек җирдә дә Синең ихтыярың гамәлгә ашсын; көндәлек икмәгебезне безгә бүген бир; без дә үзебезгә явызлык кылучыларны кичергәндәй, безнең явыз эшләрне Син кичер.*

Ислам пәйгамбәренең үз исеме урынына кулланылган *Пәйгамбәребез, Рәсүлуллаһ* кебек сүзләр баш хәрефтән языла, мәс.: *Әүвәл бит Пәйгамбәребез заманасында да монафикълар булган* (Г. Исхакый). Ләкин әгәр дә мондый сүзләр янында аның үз исеме килсә, алар юл хәрефеннән языла, мәс.: *күптән пәйгамбәребез Мөхәммәднең тормыш юлын өйрәнәм; Мөхәммәд рәсүлуллаһның сөннәте.*

**Искәрмә 2.** Татар телендә кушылып языла торган сүзләрнең икенче (өченче) компоненты булып килгәндә, *Алла(һ)* сүзе юл хәрефеннән языла, мәс.: *валлаһи, билләһи, таллаһи, бисмилләһиррахманиррахим, рәсүлуллаһ, саллаллаһу галәйһи вәсәлләм.*

**Искәрмә 3.** Әгәр дә *раббы* сүзе ыру атамасы функциясендә килсә, юл хәрефеннән языла, мәс.: *Кешене, раббым — Аллаһ, дигән өчен үтерәсезме?; шушы Кәгъбәтулланың раббысына гыйбадәт кылсыннар; Фиргавен: «Сезнең бөек раббыгыз — мин!» — диде.*

**Искәрмә 4.** Фразеологизмнар һәм ымлыклар составында *Аллаһ* һәм аның урынына кулланыла торган бөтен сүзләр дә баш хәрефтән языла, мәс.: *Алар бит үзләрен Алланың кашка тәкәсе дип саный* (Г. Галиева). *Ай Алла, балалар, таеп китә күрмәгез инде* (А. Әхмәтгалиева). *Шулкадәр дөбер дә шатыр җыр-музыка буламы, Ходавәндә!* (Ш. Галиев).

**3.** Ялгызлык исем мәгънәсендә кулланылган һәм диндә үтә әһәмиятле булып саналган төшенчәләрне баш хәрефтән язу киңәш ителә, мәс.: *Кыямәт көне, Хисап көне, Мәхшәр мәйданы, Сур, Сыйрат (күпере), Гареш; Сүз (Иң башта Сүз булган), Изге Серләр, Изге Бүләкләр.*

**4.** Дини бәйрәмнәр исемендә беренче (яки бердәнбер) сүз баш хәрефтән языла, мәс.: *Корбан гаете (бәйрәме), Ураза бәйрәме (гаете), Мигъраҗ кичәсе, Бәраәт кичәсе, Мәүлид, Гашура; Олы көн, Пасха, Раштуа, Труйчын, Май чабу, Хачманар, Покрау, Питрау, Нардуган, Элҗен; Ханука, Шаббат* һ. б.

> **Искәрмә.** Дини бәйрәмнәр исәпләп чыгарыла торган календарь айларының исемнәре юл хәрефеннән языла, мәс.: *рәҗәп, шәгъбан, рамазан, зөлхиҗҗә, зөлкагдә*.

**5.** Конфессия исемнәре һәм аларның төрле юнәлешләре юл хәрефеннән языла, мәс.: *ислам, христианлык, яһүдилек, буддизм, православие, лютеранлык, шигыйлык, сөннилек*.

Христианлык кысаларындагы милли дини агымнарның, оешмаларның, җәмәгатьләрнең (чиркәүләрнең) исемнәрендәге беренче сүз баш хәрефтән языла, мәс.: *Рус православие чиркәве, Молдова православие чиркәве, Искәндәрия православие чиркәве, Грек католик чиркәве, Рим католик чиркәве, Украина грек чиркәве, Әрмән апостоллар чиркәве, Евангелие лютеран чиркәве.*

**6.** Хакимият вертикале үзәкләштерелгән дини оешмаларның (беренче нәүбәттә христианлыкның) иң югары идарә органнары исемнәрендә беренче сүз баш хәрефтән языла, мәс.: *Изге синод, Бөтендөнья соборы* (рус. *Вселенский собор*). Әгәр дә бу тулы исемнәр урынына бер генә сүзле исемнәр кулланылса, алар баш хәрефтән языла — *Синод, Собор (Җыен)* (к. § 6, п. 2).

Югары чиркәү вазифаларының тулы рәсми исемнәрендә беренче сүз, исем составына кергән ялгызлык исемнәр һәм вазифа үзе баш хәрефтән языла, мәс.: *Мәскәү һәм бөтен Русь Патриархы, Бөтендөнья Константинополь Патриархы, Бөтен әрмәннәрнең баш Патриархы һәм Каталикосы, Бөтен Грузия Каталикосы-Патриархы, Рим Папасы*. Шул ук вакытта рәсми булмаган текстларда бу вазифаларның (гадәттә, тулы булмаган) исемнәре юл хәрефеннән языла, мәс.: *патриархка хат юллау, папа резиденциясе*.

Бүтән чиркәү вазифаларының һәм башка диннәрнең төрле дәрәҗәдәге рухани затларының исемнәре юл хәрефеннән языла, мәс.: *архиепископ, архиерей, архимандрит, дьякон, ая-*

*тулла, епископ, игумен, имам, казый, кардинал, митрополит, мөфти, мөхтәсиб, мулла, протодьякон.*

**Искәрмә.** *Имам Әгъзам* сүзендә *имам* кушамат (ләкабь) составында булган өчен баш хәрефтән языла.

**7.** Изге китапларның исемнәре баш хәрефтән языла, мәс.: *Коръән, Инҗил, Тәүрат, Библия, Зәбур, Талмуд, Ведалар*; изге китапның исеме урынына кулланган *Изге Китап* сүзтезмәсе, шулай ук ниндидер китапны белдерү өчен берничә сүздән гыйбарәт исемнәрдә һәр компонент баш хәрефтән языла, мәс.: *Коръә́не Кәрим, Кәлам Шәриф, Иске Гаһед, Яңа Гаһед.*

**8.** Гыйбадәт төрләре, аларның аерым өлешләренең исемнәре, вакытлары, хәрәкәтләре юл хәрефеннән языла, мәс.: *намаз, ураза, литургия, месса, тәреле (хачлы) йөреш; рәкәгать, рөкүгъ, сәҗдә, ахшам, ястү, икенде*.

## § 6. Хакимият органнары, учреждение, оешма, җәмгыять, партияләр исемнәре

**1.** Хакимият органнары, учреждение, фәнни, белем бирү һәм тамаша оешмалары, җәмгыятьләр, сәяси партияләр һ. б. ның берничә сүздән торган рәсми атамаларында беренче сүз һәм исем составына кергән ялгызлык исемнәр, шулай ук алар эчендә кулланылган башка учреждениеләрнең һәм оешмаларның беренче сүзләре баш хәрефтән языла, мәс.: *Бөтендөнья тынычлык советы, Халыкара валюта фонды, Европа парламенты (Европарламент), Европада иминлек һәм хезмәттәшлек оешмасы, Дәүләт думасы, Дәүләт советы, Генераль штаб, Конституция суды, Мәскәү хөкүмәте, Россия банклары ассоциациясе, Россия мәгълүмат телеграф агентлыгы, Россия фәннәр академиясе, Евровидение; Дәүләт Третьяков галереясы, Дәүләт академик Зур театры, Мәскәү Сәнгать академия театры, Дәүләт Рус музее* (һәм аларның рәсми булмаган исемнәре: *Третьяков галереясы, Зур театр, Сәнгать театры, Рус музее*); *Көнчыгыш халыклары сәнгате музее, Дәүләт тарих җәмәгать китапханәсе, Үзәк рәссамнар йорты, Социаль-сәяси тикшеренүләр фонды, Россия*

*Фонд биржалары федерациясенең мәгълүмат анализлау үзәге, Польша сеймы, Мәскәү патриархиясе, Үзәк универсаль кибет* (Мәскәүдә), *Халыкара олимпия комитеты, Никах сарае, Метрополитен-музей, Президент-отель.*

**Искәрмә 1.** Традиция буенча түбәндәге оешма исемнәрендә сүзләрнең барысы да баш хәрефтән языла: *Берләшкән Милләтләр Оешмасы, Милләтләр Лигасы, БМО Иминлек Советы*.

**Искәрмә 2.** Чит ил мәгълүмат агентлыклары исемнәрендә ыру атамасыннан башка сүзләр барысы да баш хәрефтән языла, мәс.: *Франс Пресс агентлыгы, Пресс Интернэшнл агентлыгы*.

**Искәрмә 3.** Рус теленнән аермалы буларак, татар телендә хакимият органнары, учреждение, фәнни һ. б. оешмаларның исемнәре субъект (ил, дәүләт) атамасыннан соң, шулай ук исем составындагы билгеле бер шәхеснең исем-фамилиясеннән соң баш хәрефтән языла, мәс.: *РФ Федераль собраниесе, РФ Югары арбитраж суды, РФ Генераль прокуратурасы, Россия Федерациясенең Тышкы эшләр министрлыгы, Россия Федерациясенең Дәүләт статистика комитеты, РФ Коммунистлар партиясе, Россия Журналистлар берлеге, М. С. Щепкин исемендәге Театр училищесы, РФА В. В. Виноградов исемендәге Рус теле институты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, АКШ Югары суды.*

**2.** Әгәр дә оешманың тулы исеме урынына ким исем кулланылса, беренче (яки бердәнбер) сүз баш хәрефтән языла, мәс.: *Дәүләт думасы — Дума, Дәүләт әдәбият музее — Әдәбият музее, Үзәк рәссамнар йорты — Рәссамнар йорты, Мәскәү консерваториясенең Зур залы — Консерваториянең Зур залы, Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институты — Халыкара мөнәсәбәтләр институты.*

**3.** Чит илләрнең югары сайлаулы учреждениеләренең исемнәре, гадәттә, юл хәрефеннән языла, мәс.: *парламент, лордлар палатасы, общиналар палатасы, рейхстаг, бундесрат, сейм, стортинг, риксдаг, АКШ конгрессы* (*сенат* һәм *вәкилләр палатасы*), *мәҗлес.* Ләкин *Дәүләт собраниесе, За-*

*кон чыгару собраниесе, Халык палатасы, Милли собрание* кебек исемнәрдә баш хәреф кулланыла.

**4.** Ыру атамасыннан һәм төгәлләүче төр компонентыннан торган исемнән гыйбарәт атамаларда соңгысы куштырнаклар эченә алына, аның беренче (яки бердәнбер) сүзе һәм ялгызлык исемнәр баш хәрефтән языла, мәс.: *«Россия» кунакханәсе, «Скифлар алтыны» күргәзмәсе, «Юбилейный» спорт сарае, «Урак һәм чүкеч» металлургия заводы, «Наука» нәшрияты, «Виртуозы Москвы» камера оркестры, «Казалмаззолото» консорциумы, «Народная воля» партиясе, «Россия хатын-кызлары» сәяси хәрәкәте, «Кызыл Октябрь» кондитер фабрикасы, «Көньяк машина төзү заводы» җитештерү комплексы, «Арбат» казиносы, «Динамо» спорт җәмгыяте, «Стрела» спорт клубы, «Мир» кинотеатры, «Трансэнергомонтаж» тресты, «Петровский пассаж» кибете, «Пежо» автомобиль концерны, «Панасоник» фирмасы, «Россия товар-чимал биржасы» акционерлар җәмгыяте, «Юнайтед фрут компани» фирмасы, «Интерфакс» агентлыгы.*

**5.** Ялгызлык исемнәр булмаган учреждениеләрнең, уку йортларының һ. б. ның, шулай ук учреждение һәм оешма бүлекләренең һәм өлешләренең исемнәре юл хәрефеннән языла, мәс.: *торак мәйданын алмаштыру бюросы, шәһәр элемтә бүлеге, кадрлар бүлеге, учёт секторы, торак төзелеше кооперативы идарәсе, халык депутатларының район советы, президиум, гыйльми совет, сәнгать советы, журналистика факультеты, чит телләр кафедрасы.* Мондый исемнәрне аерып күрсәтер өчен, цифрлар яки хәрефле билгеләр, «*фәлән исемендәге*» сүзләрен кулланырга мөмкин: *№ 266 мәктәп, Маяковский исемендәге мәктәп, № 9 автобаза, № 5 азык-төлек кибете, 12 нче дивизия, Киров исем. колхоз.*

## § 7. Документ, һәйкәл, сәнгать әйберләре һәм әсәрләре исемнәре

**1.** Мөһим документлар һәм документ җыентыклары, дәүләт законнары, шулай ук архитектура һәйкәлләре һ. б. ш. ядкәрләр, сәнгать әйберләре һәм әсәрләренең тезмә

исемнәрендә беренче сүз һәм ялгызлык исемнәр баш хәрефтән языла, мәс.:

*Федератив шартнамә, Тынычлык турында декрет, Кеше хокукларының гомуми декларациясе, Хезмәт турында законнар кодексы, Гражданлык законнары нигезләре, Качаклар буенча дәүләт конвенциясе, Ирекләрнең бөек хартиясе, Кызыл китап* (саклана торган хайваннар һәм үсемлекләр исемлеге), *Гиннесның рекордлар китабы;*

*Сикст капелласы, Исаакий соборы, Зур Кремль сарае, Арча зираты, Елагин сарае, Кышкы сарай, Бөек Кытай дивары, Триумфаль арка // Триумф аркасы, Бакыр җайдак* (һәйкәл), *Ми́лос Венерасы, Ро́дос колоссы, Гәрәбә бүлмә* (Царское Селода), *Эйфель манарасы, Патша чаң, Патша туп; Бетховенның Тугызынчы симфониясе, Шопенның Икенче балладасы, Чайковскийның Фортепиано өчен беренче концерты, Шостаковичның Ленинград симфониясе, Бетховенның Ай сонатасы.*

**Искәрмә 1.** *Россия Федерациясе Конституциясе, БМО Уставы, РФ Җинаять кодексы* кебек документларның һ. б. ш. ның исемнәрендә субъект (ил, дәүләт яки оешма) атамасыннан соң килә торган сүз баш хәрефтән языла. Шулай ук к. § 6, искәрмә 3.

**Искәрмә 2.** Изге төшенчәләрне белдерә торган *Билгесез Солдат Кабере, Елау Дивары, Дан Аллеясы, Үлемсезлек Курганы, Хәтер Китабы* кебек мемориаль корылмалар һәм документ җыентыклары исемнәрендә беренче сүз дә, аннан соңгы сүзләр дә баш хәрефтән, ләкин *Мәңгелек ут* тезмәсендә беренче сүз генә баш хәрефтән языла.

**Искәрмә 3.** Сәнгать стильләре исемнәре юл хәрефеннән языла, мәс.: *ампир, барокко, готика, рококо, ренессанс* (*Ренессанс*ның чор исеме мәгънәсе тур. к. § 4, п. 1).

**2.** Әдәби һәм фәнни әсәрләрнең исемнәре, сәнгать әсәрләре, документлар, вакытлы матбугат һ. б. ш. исемнәре куштырнаклар эченә алына, һәм аларда беренче (яки бердәнбер) сүз һәм ялгызлык исемнәр баш хәрефтән языла. Аларга түбәндәгеләр керә:

а) ыру атамасы әсәр һ. б. исеме составына кермәгән исемнәр, мәс.: *«Дворян оясы» романы, «Эт белән дама» хикәясе, «Кавказ әсире» поэмасы, «Кара пулат» операсы, «Өч аяклы*

*ат» фильмы, «Иделдәге бурлаклар», «Юкәләр саргая» картиналары, «Сагыш» скульптурасы, «Юпитер» симфониясе, «Ватаным Татарстан» газетасы, «Казан утлары», «Фәнни Татарстан» журналлары, «Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр» законы, «Тынычлык хакына партнёрлык» программасы, «Синтаксис һәм стилистика» җыентыгы;*

ә) ыру атамасы белән сүзтезмә тәшкил итә торган әдәби әсәрләр һәм газета-журнал исемнәре, мәс.: *«Игорь полкы турында сүз», «Чын кеше турында повесть», «Безнең гәҗит»*.

**Искәрмә.** Әгәр дә сәнгать әсәренең исеме *яки* (*яисә, яхуд*) теркәгече ярдәмендә бәйләнгән ике исемнән гыйбарәт булса, икенче атаманың беренче сүзе дә баш хәрефтән языла, мәс.: *«Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә», «Шәкерт, яхуд Бер тәсадеф», «Яфрак асты, яхут Мәкәрҗә ярминкәсе».*

## § 8. Вазифа, титул, дәрәҗә исемнәре

**1.** Вазифа, титул, дәрәҗә исемнәре юл хәрефеннән языла, мәс.: *президент, канцлер, рәис, министр, премьер-министр, министр урынбасары, мэр, император, королева, хан, шәех, генераль секретарь, атказанган мәдәният хезмәткәре, Нобель премиясе лауреаты, илче, атташе, директор, академик, фәннәр докторы, профессор, мөхбир әгъза, генерал-майор, гаскәр башы, департамент җитәкчесе, бүлек мөдире.*

Рәсми текстларда югары дәүләт вазифалары һәм титуллары исемнәре баш хәрефтән языла, мәс.: *Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Рәисе, РФ Хөкүмәт Рәисе, Дәүләт думасы Рәисе, Һиндстанның Премьер-министры* (к. ш. ук § 11, п. 1). Ләкин рәсми булмаган текстларда әлеге исемнәр юл хәрефеннән языла, мәс.: *президент сайлаулары, Дәүләт думасы рәисе чыгышы, премьер-министр карары.*

**Искәрмә 1.** *Россия Федерациясе Герое* һәм элекке СССРдагы *Советлар Союзы Герое, Социалистик Хезмәт Герое* шәрәфле исемнәрнең һәр сүзе баш хәрефтән языла.

**Искәрмә 2.** Дин әһелләре вазифалары исемнәре турында к. § 5, п. 6.

## § 9. Орден, медаль, премия, шәрәфле билгеләр исемнәре

Ыру төшенчәсе белән синтаксик бәйләнештә булмаган орден, медаль, премия, аерымлык билгеләре исемнәре куштырнаклар эченә алына һәм беренче сүзләре һәм ялгызлык исемнәр баш хәрефтән языла, мәс.: *«Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены, «Хезмәт ветераны» медале, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале, «Маршал йолдызы» билгесе, «Халык мәгарифе отличнигы» билгесе, «Алтын битлек» премиясе.*

Шәрәфле билгеләрнең башка исемнәре куштырнаклар эченә алынмый, һәм аларның беренче сүзләре, шулай ук исем составындагы ялгызлык исемнәр баш хәрефтән языла, мәс.: *Дуслык ордены, «Дуслык» ордены*[1], *I дәрәҗә Ватан сугышы ордены, Шәрәфле легион ордены* (Франция), *Изге Георгий ордены, Аналык медале, Георгий тәресе; Дәүләт премиясе, Нобель премиясе.*

**Искәрмә.** Элекке СССР орденнарының кайбер исемнәрендә, *орден* сүзеннән тыш, барлык сүзләр дә баш хәрефтән языла, мәс.: *Кызыл Байрак ордены, Октябрь Революциясе ордены.*

## § 10. Товар билгеләре, марка, әйберләр һәм сортлар исемнәре

**1.** Авыл хуҗалыгы культуралары, яшелчә, чәчәк төрләренең һәм сортларының шартлы исемнәре — агрономия һәм бакчачылык терминнары — куштырнаклар эченә алына һәм юл хәрефеннән языла., мәс.: *«виктория» җиләге, «мальборо» кура җиләге, «кара принц» тюльпаны.*

**Искәрмә.** Үсемлекләрнең һәм аларның сортларының гомумкабул ителгән исемнәре традиция буенча куштырнаклар эченә алынмый, мәс.: *георгин, ак налив, антоновка, розмарин, ренклод, каротель.* Сорт яки төр составына

[1] Бу очракта традиция буенча Россия Федерациясе дәүләт бүләге куштырнакларсыз языла, Татарстан Республикасы дәүләт бүләге куштырнаклар эченә алына.

кергән ялгызлык исемнәр баш хәрефтән языла, мәс.: *Пётр әвернәсе, Сөләйман мөһере; Фишер канәфере.*

**2.** Товар билгеләре, азык-төлекнең һәм башка товарларның шартлы исемнәре куштырнаклар эчендә һәм баш хәрефтән языла, мәс.: *«Российский» сыры, «Докторская» колбасасы, «Ромашка» конфеты, «Гөлҗиһан» сабыны, «Мальборо» сигареты, «Кояшлы үзән», «Үгез каны», «Монастырь өе», шәраблары, «Айгешат» портвейны.*

**Искәрмә.** Шәраб, минераль сулар һ. б. эчемлек сортларының исемнәре куштырнакларсыз һәм юл хәрефеннән языла, мәс.: *портвейн, шампан, мадера, кагор, рислинг, ессентуки-17.*

**3.** Машина, прибор һ. б. техник эшләнмәләрнең җитештерү маркалары исемнәре куштырнаклар эчендә һәм баш хәрефтән языла, мәс.: *«Москвич-412», «Волга», «Вольво», «Жигули» автомобильләре, «Боинг-707», «Руслан» самолётлары, «Эврика» кер юу машинасы, «Бирюса», «Минск» суыткычлары, «Панасоник» видеомагнитофоны.* Әмма бу әйберләрнең үзләренең исемнәре (шәхси һәм географик ялгызлык исемнәр белән туры килмәгән исемнәрдән тыш) куштырнаклар эчендә юл хәрефеннән языла, мәс.: *«москвич», «тойота», «вольво»* (автомобильләр), *«боинг», «фантом»* (самолётлар), *«панасоник»* (магнитофон); ләкин: *«Волга», «Ока», «Таврия»* (автомобильләр), *«Руслан»* (самолёт), *«Минск»* (суыткыч); чыгарма: *«жигули», «мерседес»* (автомобильләр).

**Искәрмә 1.** Җитештерү маркаларының һәм эшләнмәләренең аббревиация юлы белән ясалган исемнәре куштырнакларсыз языла, мәс.: *ЗИЛ, ВАЗ, УАЗ, КамАЗ, Ту-104.*

**Искәрмә 2.** Транспорт чараларының көнкүрештә кулланыла торган исемнәре куштырнакларсыз да була ала, мәс.: *Иске москвичта, өр-яңа кадиллакта килгән.*

## § 11. Баш хәрефтән язылган сүзләрнең махсус стилистик кулланылышы

**1.** Рәсми документлар, хәбәрләр, килешүләр текстларында кайбер исемнәр баш хәрефтән языла, мәс.: *Югары*

*Килешүче Яклар, Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илче* — халыкара актларда, дипломатик документларда; *Автор, Нәшрият* — авторлык килешүендә; *Президент, Премьер-министр, Япония Императоры* — югары дәрәҗәдә очрашулардагы документларда.

**Искәрмә.** Дин белән бәйле булган исемнәр турында к. § 5. п. 3, п. 6.

Хатларда, рәсми документларда һ. б. да конкрет бер генә кешегә хөрмәт белдерү формасы буларак *Сез* алмашлыгы баш хәрефтән языла, мәс.: *Барыбыз да Сезне тәбрик итәбез! ...шул уңайдан Сезгә... булуын хәбәр итәбез.*

**2.** Аерым югары мәгънә салынган контекстларда кайбер уртаклык исемнәр баш хәрефтән язылырга мөмкин: *Ватан, Ирек, Намус, Кеше, Остаз, Оста* һ. б.

## КЫСКАРТЫЛМАЛАР

*адм.-терр.* — административ-территориаль
*археол*. — археология
*архит*. — архитектура
*астр*. — астрономия
*б. э. к.* — безнең эрага кадәр
*библ.* — библеизм
*бот*. — ботаника
*вет.* — ветеринария
*геогр*. — география
*геол*. — геология
*дини* — дини сүз
*әд*. — әдәби
*зоол*. — зоология
*иск*. — искергән сүз
*к*. — кара
*крш.* — керәшен
*кулин.* — кулинария термины
*күч*. — күчерелмә мәгънәдә
*кыск.* — кыскартылма
*лингв*. — лингвистика
*мат*. — математика
*махс*. — махсус термин
*мед*. — медицина
*мәгъ*. — мәгънәдә, мәгънәсендә
*мәс.* — мәсәлән
*мифол*. — мифология
*муз.* — музыка
*программ.* — программалау
*сөйл*. — сөйләм телендә
*тар*. — тарихи
*тат.* — татар теле
*тур.* — турында
*фәлс*. — философия
*физ*. — физика
*физиол*. — физиология
*фольк*. — фольклор
*фразеол.* — фразеологизм
*функ*. — функция
*хим*. — химия
*хрс.* — христианлык
*ш. ук* — шулай ук
*этн*. — этнография
*юг*. — югары стиль

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

| | | | |
|---|---|---|---|
| Аа | Зз | Пп | Чч |
| Әә | Ии | Рр | Шш |
| Бб | Йй | Сс | Щщ |
| Вв | Кк | Тт | ъ |
| Гг | Лл | Уу | Ыы |
| Дд | Мм | Үү | ь |
| Ее | Нн | Фф | Ээ |
| Ёё | ң | Хх | Юю |
| Жж | Оо | Һһ | Яя |
| Җҗ | Өө | Цц | |

# А

**ААҖ** [ааҗә] (*кыск.:* ачык акционерлар җәмгыяте)
**Абака́н даласы́**
**Абака́н сырты́**
**«АББА»** *һәм* **«Абба»** (*рок төркеме*)
**Абала́к** (*Себер ханлыгындагы татар шәһәре, хәзер авыл*)
**Аба́шево культу́расы** (*археол.*)
**Аба́шево кабиләләре́** (*археол.*)
**аба́шеволылар** (*археол.*)
**аббатлы́к**, *мәс.:* Вестминстер аббатлыгы
**Абдалла́һ бин Тәки́н** (*Болгар хөкемдары*)
**Абдулла́һ бин Микаи́л** (*Болгар хөкемдары*)
**Абду́л Саламаны́** (*авыл*)
**А́бель**: **А́бель билгесе́**, **А́бель дифференциа́ль тигезләмәсе́**, **А́бель теоре́малары**, **А́бель төркеме́**
**Абельма́н Заста́васы** (*Мәскәүдәге мәйдан*)
**Аберге́ле кәҗә́ токымы́**
**Аберди́н-Ангу́с токымлы́ сыерла́р**
**абза́р иясе́** (*мифол.*)
**Абисси́ния** (*тар.*) *һәм* **Хәбәшста́н** (*тар.*)
**Або́ солыхы́** (*1743*)
**Абонда́нс**[1] (*Франция муниципалитеты*)
**абонда́нс**[2] (*сыер токымы, сыр сорты*)
**Абуга́** (*Себер ханлыгындагы татар шәһәре*)
**Абха́зия сырты́** (*геогр.*)
**Абха́зия кәҗә́ токымы́**
**абһира́ти** (*буддизмда: оҗмах*)
**абызла́р хәрәкәте́** (*XVIII—XIX гасыр*)
**абыйлы́-сеңелле Гобәйду́ллиннар** (*этнографлар Габделкадыйр Салих улы Гобәйдуллин һәм Мәрьям Салих кызы Гобәйдуллина*)
**Ава́р ханлыгы́** (*тар.*)
**Ава́ча со́пкасы** (*Камчаткада*)
**А́вгий абзарлары́** (*бик пычрак урын*)
**А́ве Мари́я** (*дини җыр*)
**авеню́** (*Американың эре шәһәрләрендә: урам*), *мәс.:* Бишенче́ (5 нче) авеню́, Унынчы́ (10 нчы) авеню́ (*Нью-Йоркта*)

**Аве́ста** (*зәрдөштлектә изге китаплар җыелмасы*)
**авиали́нияләр**: **Вну́ково авиали́нияләре** (*компания*)
**Авога́дро**: **Авога́дро законы́**, **Авога́дро саны́**, **Авога́дро конста́нтасы**
**Авро́ра**[1] (*мифол., исем*)
**авро́ра**[2] (*таң*)
**Австра́лия** (*материк, ил*), *мәс.:* Австра́лия зәңгәркүзе́ (*балык*), Австра́лия ехи́днасы, Австра́лия ке́лписы (*эт токымы*), Австра́лия торнасы́ (*зоол.*)
**Австра́лия-А́зия урта́ диңгезе́**
**Австра́лия А́льплары** (*геогр.*)
**Австра́лия-Анта́рктика казанлыгы́** (*Көньяк океанда*)
**Австра́лия кара́ кәҗә́ токымы́**
**Австра́лия Кордильерлары́** (*таулар*)
**австра́лияле**
**Австра́лия платфо́рмасы** (*геол.*)
**А́встрия пи́нчеры** (*эт токымы*)
**а́встрияле**
**А́встрия Респу́бликасы** (*рәсми*)
**А́встро-Ве́нгрия** (*тар.*)
**А́встро-Ве́нгрия импе́риясе** (*тар.*)
**авы́л советы́**
**автокефа́лия** (*хрс.*), *мәс.:* рус автокефалиясе, грек автокефалиясе
**автоно́мияле өлкә́** (*адм.-терр. берәмлек*)**: Яһүд автономияле өлкәсе**
**автоно́мияле о́круг** (*РФта адм.-терр. берәмлек*), *мәс.:* Чуко́тка автономияле округы, Эвенк автономияле округы, Ямал-Ненец автономияле округы
**автоно́мияле райо́н** (*Кытайда адм.-терр. берәмлек*), *мәс.:* Синьцзян-Уйгур автономияле районы, Тибет автономияле районы
**а́втор**[1]
**А́втор**[2] (*китап бастыру шартнамәсендә*)
**автошәһә́р**
**авы́з ачу́**[1] (*ифтар*)
**авы́з ачу́**[2] (*крш. Раштуага каршы төн*)
**ага**[1] (*абый*)
**Ага́**[2] (*Байкал Аръягындагы елга*)
**Ага́ База́р** (*тар. Болгарда сәүдә үзәге*)
**Ага́ даласы́** (*Байкал Аръягында*)
**Агаме́мнон** (*мифол.*)
**Агасфе́р** (*персонаж, Мәңгелек яһүди*)
**Ага́та Кри́сти**
**Ага́ хан** (*исмәгыйлиләрдә имам титутлы*)
**агентлы́к**, *мәс.:* Евро́па ко́смик агентлыгы́, Рейтер

агентлыгы́ (*Бөекбритания*), «Татар-инфо́рм» агентлыгы́, «Татме́диа» респу́блика матбуга́т һәм ма́ссакүләм коммуника́цияләр агентлыгы́, Яңалыкла́р һәм мәгълүма́т агентлыгы́

**Агни́** (*индуизмда: ут илаһы*)

**Аграха́н култыгы́**

**Аграха́н ярымутравы́**

**Агри́пна д’Обинье́** (*француз шагыйре, тарихчы*)

**Агыйде́л** (*елга*)

**«Агыйде́л» дәүлә́т җыр һәм бию́ анса́мбле**

**Адә́м**[1] (*дини*): Адәм белән Хәүва, Адәм галәйһиссәлам

**адә́м**[2] (*кеше, инсан*), *мәс.:* адәм баласы, адәм актыгы, адәм мәсхәрәсе

**Адә́м Күпере́** (*Һиндстан белән Цейлон арасындагы кыя һәм сайлыклар тезмәсе*)

**А́ддисон авыруы́**

**Адди́с-Абе́ба** (*Эфиопия башкаласы*)

**«Адида́с»**[1] (*фирма, марка*)

**адида́с**[2] (*эшләнмәләр тур.*), *мәс.:* адидас кроссовкалары, адидастан йөрү

**администрати́в о́круг**, *мәс.:* Көнбатыш административ округ (*Мәскәүдә*)

**администра́ция**, *мәс.:* шәһәр администрациясе, Алтай крае администрациясе

**адмира́л**[1], *мәс.:* адмирал Ушаков, флот адмиралы, *ләкин* Советлар Союзы Флоты Адмиралы

**Адмира́л**[2] (*урам атамаларында*), *мәс.:* Адмирал Ушако́в урамы (*Казанда*)

**адмира́л**[3] (*күбәләк*)

**Адмиралте́йство бистәсе́** (*Казанда*)

**Адмиралте́йство конто́расы** (*Казанда архитектура һәйкәле*)

**Адо́нис урманы́** (*тыюлык*)

**Адо́ теоре́масы**

**Адыге́я** (*РФ субъекты*)

**Адыге́я сыры́** (*ш. ук* **чиркәс сыры**; адыгей сыры *дию ялгыш*)

**«Адыге́я сыры» фестива́ль-конкурсы́**

**Адыге́я Респу́бликасы** (*рәсми*)

**аждаһа́**[1] (*мифол.; кеше тур.*)

**Аждаһа́**[2] (*тау, персонаж*)

**Аждаһа́**[3]: **Аждаһа́ елы́** (*Көнчыгыш календаре буенча унике еллык циклның бишенче елы*); **Аждаһа́** (*шул елда туган кеше*)

**АҖ** [аҗэ́] (*кыск.:* акционерла́р җәмгыяте́)

**Аҗа́рия сырты́** (*субүләр*)

**Аҗа́рия Автоно́мияле Респу́бликасы**

**Аҗарста́н** (*Грузиядә*)

**Аза́к** (*иск.*) *һәм* **Азо́в** (*шәһәр*)

**Аза́к диңгезе́** (*иск.*)

**Азатлы́к мәйданы́** (*Яр Чаллыда*)

**«Азатлы́к» тата́р яшьләре́ берлеге́**
**«Азатлы́к ра́диосы»**
**Азатлы́к утравы́** (*Куба тур.*)
**Азатлы́к һәйкәле́**
**азәрбайҗан**[1] (*этноним*), *мәс.:* азәрбайҗан теле, азәрбайҗан әдәбияты
**Азәрбайҗа́н**[2] (*дәүләт*), *мәс.:* Азәрбайҗан территориясе
**Азәрбайҗа́н Респу́бликасы** (*рәсми*)
**азәрбайҗа́н каты́ йонлы́ кәҗә́ токымы́**
**«Аза́т хаты́н»** (*журнал*)
**Азе́лино культу́расы** (*археол.*)
**Азе́лино кабиләләре́** (*археол.*)
**азе́линолылар** (*археол.*)
**Азиа́да** (*Азия уеннары*)
**А́зия** (*континент*), *мәс.:* Азия илләре, Россиянең Азия өлеше; Азия ланцетнигы (*зоол.*)
**А́зия басмаханәсе́** (*Казанда*)
**А́зия депре́ссиясе** (*геогр.*)
**А́зия-Тын океа́н регионы́**
**А́зия-Тын океа́н икътисади́ хезмәттәшлеге́**
**А́зия уеннары́** (*Азия илләре атлетлары ярышы*)
**Азнака́й** (*шәһәр, район*)
**Азнака́й аучылы́к тыюлыгы́**
**Азо́в** *һәм* **Аза́к** (*шәһәр*)
**Азо́в диңгезе́**
**Азо́в походлары́** (*1695—1696*)
**Азо́р таулары́** (*архипелаг*)
**Аи́д** (*астр.*)
**Ай**[1] (*күк җисеме*), *мәс.:* Айны өйрәнү, Ай төзелеше, Ай атласы
**ай**[2] (*башка мәгънәләрдә*), *мәс.:* ай яктысы, ай урагы; август ае, рамазан ае
**Айболи́т** (*персонаж*)
**айма́к** (*Монголиядә адм.-терр. берәмлек*), *мәс.:* Гоби-Алтай аймагы
**Ай-Пе́три** (*тау*)
**Айрши́р** (*Шотландия графлыгы*)
**Айрши́р сые́р токымы́**
**Айсин-Гиоро́ Пу И** *яки* **Пуи́** (*Кытай императоры*)
**Айясо́фья** (*Истанбулдагы мәчет*)
**Ай-Тодо́р** (*геогр. борын*)
**айфо́н** (*Apple смартфоны*)
**Ака́бә култыгы́**
**акаде́мик**[1] (*академия әгъзасы*)
**Акаде́мик**[2] (*геогр. атамаларда, урам исемнәрендә һ. б. да*), *мәс.:* Академик Завойский урамы, Академик Глушко урамы (*Казанда*), Академик Обручев сыртлары
**акаде́мия**[1] (*оешма*), *мәс.:* Болгар ислам академиясе, Казан дәүләт медицина академисе, К. А. Тимирязев исемендәге Мәскәү авыл хуҗалыгы академиясе, Россия фәннәр академиясе, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе

**академия**[2] (*хор, театр, ансамбль, оркестр исемнәрендә — «югары дәрәҗәдәге, үрнәк» мәгъ.*), *мәс.:* Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры, Рус халык уен кораллары академия оркестры
**Академия**[3] (*Афинада Платонның фәлсәфә мәктәбе*)
**Академия**[4] (*геогр. атамаларда «исемендәге» мәгъ.*), *мәс.:* Академия култыгы (*Охота диңгезендә*), Фәннәр Академиясе сырты (*Памирда*)
**Академия бистәсе** (*Казанда*)
**ак амур** (*балык*)
**Акатуй каторга төрмәсе** (*тар.*)
**Ак Байтал** (*персонаж*)
**ак барс**[1] (*зоол.*)
**«Ак барс»**[2] (*банк; хоккей клубы*)
**Ак Барыс** (*мифол.*)
**акбур чоры** (*геол.*)
**Акбүзат**[1] (*фольк.*)
**акбүз ат**[2]
**Акбүзат йолдыз**
**ак бүре**[1] (*мифол.*)
**Ак Бүре**[2] (*персонаж*)
**Акбүре**[3] (*авыл*)
**Аквилея** (*тар., Италиядәге шәһәр*)
**Аквилея кәҗә токымы**
**Акваридалар** (*метеорлар агымы*)
**Аквилон**[1] (*мифол.*)
**аквилон**[2] (*төньяк җиле*)
**Ак гвардия**
**акгвардияче**
**Ак диңгез**; Ак диңгез сельде
**Ак диңгез-Балтыйк каналы**
**Ак Елан** (*персонаж*)
**Акита**[1] (*Япониядәге префектура*)
**акита**[2] (*эт токымы*)
**акита-ину** (*эт токымы*)
**Ак йорт** (*АКШ президенты резиденциясе*)
**Аккад**[1] (*тар., шәһәр*)
**аккад**[2] (*этноним*), *мәс.:* аккад теле
**Аккирмән** (*тар.*)
**Ак китап** (*документлар җыелмасы*)
**аккош**[1] (*зоол.*)
**Аккош**[2] (*йолдызлык*)
**«Аккош күле»** (*урман паркы*)
**Аккош күлләре** (*күлләр системасы*)
**Ак Кумания** (*тар.*)
**Ак Күбек** (*фольк.*)
**Ак Күбек хан** *һәм* **Аккүбәк хан** (*Әстерхан ханы*)
**аккүз**[1] (*балык, кош*)
**Аккүз**[2] (*авыл*)
**Ак күл** (*тар. күл*)
**Аккүл Бигәнәй** (*авыл*)
**Акмәчет**[1] (*тар.,* **Симферополь**; *шулай ук Кырымда, Казакстанда һ. б. да төрле торак пунктлар*)
**Ак мәчет**[2] (*Казан, Болгар, Яр Чаллы, Әстерхан, Томск, Хива һ. б. күп кенә шәһәрләрдә*)
**Ак Нил** (*Нилнең сул кушылдыгы*)

**Ак олимпиа́да** (*кышкы олимпиада*)
**ак патша́** (*рус патшасы*)
**Ак пула́т** (*Болгарда тарихи һәйкәл*)
**акро́поль**[1] (*Борынгы Греция шәһәрләрендә: кальга*)
**Акро́поль**[2] (*Афинада*)
**Акса́й** (*елга; төрле торак пунктлар*)
**Акса́к Тиме́р** (*әмир*)
**Акса́к Карату́н** (*епископ Лука Конашевич*)
**а́ксель** (*фигуралы шууда сикерү төре*)
**Аксуба́й ага́ч эшкәртү́ заводы́**
**Актаны́ш муниципа́ль дра́ма һәм коме́дия теа́тры**
**Акта́ш упкыны́** (*геол.*)
**Актео́н** (*мифол.*)
**Актёрлар ги́льдиясе пре́миясе**
**Актүбә́** (*шәһәр, авыл, посёлок*)
**Актүбә́ урма́н массивы́** (*тыюлык*)
**Актүбә́ фосфори́т бассе́йны**
**акт** (*документ, карар*), *мәс.:* Германиянең капитуляциясе акты (*1945*), гражданлык хәле актлары
**Актёрла́р йорты́**
**Ак Урда́** (*тар.*)
**акционерла́р җәмгыяте́ (АҖ)**
**АКШ** [а́кш] *һәм* [а́кыш] (*кыск.:* Аме́рика Кушма́ Штатлары́)
**А́КШның А́рктика яр буе́**
**Акыллы́ Карл** (*Франция короле Карл V*)
**Акылсы́з Карл** (*Франция короле Карл VI*)
**Акъя́б** (*Мьянмадагы шәһәр*)
**Акъя́б кәҗә́ токымы́**
**ак эмигра́ция**
**алаба́й**[1] (*эт токымы*)
**Алаба́й**[2] (*эт кушаматы*)
**Алабуга́**[1] (*шәһәр*)
**алабуга́**[2] (*балык*)
**«Алабуга» махсус иктисади зонасы**
**Алабуга́ педаго́гика институ́ты́**
**Алабуга́ тари́х, архитекту́ра һәм сәнга́ть музе́йсаклаулыгы́**
**Ала́й А́ръягы та́у сырты́**
**ала́н**[1] (*урманда*)
**Ала́н**[2] (*авыл*)
**Ала́н Биксе́р** (*авыл*)
**Ала́н Җөри́** (*авыл*)
**Ала́т даругасы́** (*тар.*)
**Алата́у**[1] (*Казакстан, Себер тау чылбырлары атамаларында*), *мәс.:* Җуңгар Алатавы, Кузнецк Алатавы, Кыргыз Алатавы; (*Башкортстанда урманлы тау сырты*)
**Алата́у**[2] (*Казакстан, Төрекмәнстандагы торак пунктлар*)
**Алата́у сые́р токымы́**
**Алаты́р** (*шәһәр*)
**Алафу́зов фа́брикасы**
**Алафу́зов теа́тры** (*Казанда*)
**Алба́ния** (*дәүләт*)

**Алба́ния кәҗә́ токымы́**
**Алба́ния Респу́бликасы** (*рәсми*)
**алба́нияле**
**Алба́с** (*елга*)
**Алба́с кәҗә́ токымы́**
**Албасты́** (*мифол.*)
**Алга́**[2] (*авыл*)
**«Алга́»**[3] (*газета*)
**Алга́ Көе́к** (*авыл*)
**Алга́рви**[1] (*Португалиядәге регион*)
**алга́рви**[2] (*кәҗә токымы*)
**алго́л** (*программ.*)
**Алго́ль** (*астр.*)
**Алгы́ А́зия**
**Алда́р** *һәм* **Алда́р Таз** *һәм* **Алда́р Күсә́** (*фольк. персонажы*)
**Алда́р-Күче́м фетнәсе́** (*1704— 1711*)
**«А́ле Гыйимра́н» («Гыйимра́н гаиләсе́») сүрәсе**
**Але́кин Аланы́** (*авыл*)
**Алекса́ндра теа́тры** (*С.-Петербургта*)
**Алекса́ндр Беренче́ (Алекса́ндр I)**
**Алекса́ндр Бистәсе́** (*авыл*)
**Алекса́ндр Не́вский**
**Алекса́ндр Не́вский соборы́** (*Мәскәүдә*)
**Алекса́ндр коло́ннасы** (*С.-Петербургта*)
**Алекса́ндр Не́вский храмы́** (*Казанда һәм башка шәһәрләрдә*)
**Алекса́ндр чоры́** (*Александр I идарә иткән чор*)
**Алексе́й равелины́** (*С.-Петербургта*)
**Алексе́й — Алла бәндәсе** (*хрс. изге; персонаж*)
**Алекса́ндровлар пассажы́** (*Казанда*)
**Алексе́евлар-Са́харов йорты́** (*Казанда*)
**Алексе́евск ко́мплексы** (*археол.*)
**Але́н Дело́н тү́гел** (*фразеол., бик матур булмаган ир кеше тур.*)
**Алеу́т та́у сырты́** (*Аляскада*)
**Алеу́т утраулары́**
**Алёша Попо́вич** (*былина персонажы*)
**Алжи́р** (*тар. Җәзаир тур.*)
**алжирлы́**
**Алжи́р Халы́к Демокра́тик Респу́бликасы** (*рәсми*)
**Алкино́й** (*мифол.*)
**алконо́ст** (*мифол.*)
**Ал мәчéт** (*Казанда*)
**Алла́(h)**, *мәс.:* Аллаһ әкбәр, Алла белсен, Алла (хакы) өчен
**Алла Анасы́** (*хрс.*)
**Алла́ Анасы́ ико́насы хөрмәтенә́ «Умиле́ние» храмы́** (*Казанда*)
**Алла́ архистра́тигы Михаи́л чаң манарасы́** (*Раифада*)
**Алла́ Ата́** (*хрс.*)
**Алла́ бәндәсе́**
**Алла́ бәндәсе́ Але́ксий** (*хрс. аскет*)
**Алла́ Изге́ Рух** (*хрс.*)
**Алла́ Изге́ Тын** (*крш.*)

**Алла́ Ул** (*хрс.*)

**Алла́һы Тәгалә́**

**алле́я**[1] (*урам, торак комплекс атамаларында*), *мәс.:* «Ак аллея» торак комплексы (*Казанда*), Гашыйклар аллеясы (*Алабугада*)

**Алле́я**[2] (*мемориаль корылма атамаларында*), *мәс.:* Дан Аллеясы, Батырлар Аллеясы

**Алматы́** (*шәһәр*)

**Алма́ Спасы́** (*дини бәйрәм*)

**Алмы́ш** (*Идел Болгары илтәбәре*)

**Алпамша́** (*персонаж*)

**Алтавы́л** (*Пенза өлкәсенең бер төркем татар авылларын берләштергән атама*), *мәс.:* Кикин — Алтавылның иң зур авылы

**алта́й**[1] (*этноним*), *мәс.:* алта́й телләре, алтай хатыны

**Алта́й**[2] (*регион*)

**Алта́й**[3] (*тау системасы*)

**Алта́й Арты́ Го́бие** (*чүл*)

**Алта́й крае́** (*рәсми*)

**Алта́й Респу́бликасы** (*рәсми*)

**Алта́й сары́к токымы́**

**алты́н**[1], *мәс.:* алтын йөзек

**Алты́н**[2] (*географик, йолдызлык, медаль, бүләк һ. б. атамаларның беренче сүзе буларак*), *мәс.:* Алтын Урда, «Алтын Йолдыз» (*медаль*), Алтын Балык (*йолдызлык*)

**«Алты́н алка́»** (*турнир*)

**Алты́н Әтә́ч** (*персонаж*)

**алты́н балы́к**[1] (*балык*)

**Алты́н Балы́к**[2] (*персонаж*)

**Алты́н Балы́к**[3] (*йолдызлык*)

**«Алты́н битле́к»** (*премия*)

**Алты́н бу́лла** (*тар.*)

**алты́н гасы́р**

«**Алты́н граммофо́н**» (*приз*)

**«Алты́н гло́бус»** (*приз*)

**алты́н запасы́** (*дәүләтнең*)

**«Алты́н Йолды́з»** (*медаль*)

**Алты́н капка́**[1] (*Киевта, Владимирда*)

**Алты́н Капка́**[2] (*бугаз*)

**«Алты́н кента́вр»** (*приз*)

**алты́н кисе́м**

**«Алты́н ма́ска»** (*приз*)

**Алты́н Мөге́з** (*бухта*)

**«Алты́н па́льма ботагы́»** (*приз*)

**Алты́н Тәхе́т** (*тар., Сарай шәһәрендәге бистә*)

**алты́н тире́** (*мифол.*)

**Алты́н тире́ о́рдены**

**Алты́н Урда́**[1] (*тар.*)

**«Алты́н Урда́»**[2] (*балет*)

**алты́н боза́у** *яки* **алты́н үге́з боза́у** (*Исраил уллары ясаган пот тур; ш. ук библ.*)

**алты́н ханы́м** (*ханның баш хатыны титулы*)

**Алтынчә́ч**[1] (*мифол., персонаж*)

**«Алтынчә́ч»**[2] (*опера*)

**Алты́н Яр** (*Африкадагы территория*)

**Ал һәм Ак розалар сугышы́** (*1455—1485*)

**алы́п**[1] (*батыр; титул*), *мәс.:* Туңгак алып, Салчак алып, яшь алып

**Алы́п**[2] (*персонаж*)
**Алыпмәмшә́н** (*дастан персонажы*)
**Алыпкарако́ш** (*мифол.*)
**Альбио́н** (*Британия утраулары*)
**Альп таулары́**
**Альп җыерчыклыгы́** (*геол.*)
**альпи́на** *һәм* **Альп кәҗә́ токымы́**
**Альп-Һимала́й җыерчыклы́к по́ясы** (*геогр.*)
**а́льфа** (*йолдыз атамаларында*), *мәс.:* Центавр альфасы (α)
**Альцге́ймер авыруы́**
**Альцио́на** (*мифол.; йолдыз*)
**алья́нс** (*союз, берләшмә*), *мәс.:* Төньяк Атлантика альянсы
**Альфо́нс**[1] (*персонаж, исем*)
**альфо́нс**[2] (*хатын-кыз асравындагы сөяркә ир*)
**Альфо́нсо җәдвәлләре́** (*астр.*)
**Аля́ска**[1] (*геогр.*)
**аля́ска**[2] (*йорт куяны токымы*)
**аля́ска**[3] (*куртка*)
**Аля́ска сырты́**
**Амазо́ния** (*Амазонка түбәнлеге*)
**Амазо́нка**[1] (*елга, түбәнлек*)
**амазо́нка**[2] (*яугир хатын*)
**амазо́нка**[3] (*сыбай йөрү өчен хатын-кыз күлмәге*)
**Аме́рика** (*материк, ил*); Америка ачу (*фразеол.*); Америка акитасы (*эт токымы*), Америка кёрлы (*мәче токымы*)
**Аме́рика Кушма́ Штатлары́ (АКШ)** (*рәсми*)
**Амита́бһа** (*ламаистларда будда*)
**Амо́н** (*мифол.*)
**Амман** (*Иордания башкаласы*)
**Аммо́н мөгезе́** (*мед.*)
**Амо́ргос** (*Грециядәге утрау*)
**Амо́ргос кәҗә́ токымы́**
**Ампе́р**[1]: **Ампе́р законы́**, **Ампе́р теоре́масы**
**ампе́р**[2] (*үлчәү берәмлеге*)
**Амудәрья́** (*елга*)
**Аму́р**[1] (*мифол.*)
**аму́р**[2] (*мәхәббәт илаһының скульптурасы яисә сурәте; матур малай, яшүсмер*)
**Аму́р**[3] (*елга*)
**аму́р**[4] (*ак амур, кара амур балыкларының гомуми атамасы*)
**«Аму́р»**[5] **но́мерлары** (*Казанда архитектура һәйкәле*)
**Аму́р Буе́** (*физик-географик өлкә*)
**Аму́р култыгы́**
**Аму́р юлбарысы́**
**Амфитри́та** (*мифол.*)
**Анадолу́ агентлыгы́** (*Төркия*)
**Анады́рь култыгы́**
**Анады́рь сырты́** (*тау сырты*)
**Ана́ньино кабиләләре́** (*археол.*)
**Ана́ньино культу́расы** (*археол.*)

**Анатóлия**
**Анатóлия карá кәҗ́ә токымы́**
**Анатóлия яссытаулыгы́** (*геогр.*)
**Анатóмия теáтры** (*Казанда*)
**Áнгельн** (*Германиядәге ярымутрау*)
**Áнгельн кәҗ́ә токымы́**
**Áнглия барóккосы**
**Áнглия түбәнлегé** (*геогр.*)
**Ангóла казанлыгы́** (*геогр.*)
**Ангóла Респýбликасы** (*рәсми*)
**ангóра токымы́** (*кәҗә, мәче токымы*)
**Анд таулары́**
**Анд сырты́** (*Кавказда*)
**Андалýзия** *һәм* **Андалýсия** *һәм* **Әндәлýс** (*Испаниядә*)
**Андóрра-ла-Вьéха** (*шәһәр*)
**Андрéа дель Сáрто** (*Италия рәссамы*)
**Андрéй байрагы́**
**Андрéй Боголю́бский** (*князь*)
**Андрéй Первозвáнный** (*апостол*)
**Андрéй Первозвáнный храмы́** (*Раифада, Яшел Үзәндә*)
**Андрéй соборы́** (*Мәскәүдә, Киевта, С.-Петербургта һ. б. Изге апостол Андрей Первозванный соборы*)
**Андрéй хачы́** (*кыек хач*)
**Андромéда**[1] (*мифол., йолдызлык*)
**Андромéда**[2] (*томанлык*)
**Андрóник монастырé** (*Мәскәүдә*)
**Андрýсово вакытлы́ солыхы́** (*1667*)
**Áндһра-Прадéш** (*Һиндстандагы штат*)
**Анжéро-Сýдженск** (*шәһәр*)
**Анжý** (*Урта гасырларда француз графлыгы*)
**Анжулáр** (*династия*)
**Ани́сья түтәлләрé** (*Биектау районындагы изге урын*)
**Ани́чков бистәсé** (*С.-Петербургта*)
**Ани́чков күперé** (*С.-Петербургта*)
**Анкарá декларáциясе** (*1998*)
**ансáмбль** (*иҗади коллектив; архит.*), *мәс.:* Татарстан Республикасы җыр һәм бию ансамбле, «Аланлык» ансамбле, «Бәрмәнчек» дәүләт фольклор ансамбле; мемориаль ансамбль
**антáнта**[1] (*тар., дүләтләр союзы*): **Уртá диңгéз антáнтасы** (*Англия, Австро-Венгрия һәм Италия, 1887*), **Кечé антáнта** (*Чехословакия, Румыния һәм Югославия, 1920—1938*)
**Антáнта**[2] (*тар., Бөекбритания, Франция һәм Россия союзы*)
**Антáрес** (*йолдыз*)
**Антаркти́да**
**Антáрктика пингвины́**
**Антáрктика платфóрмасы** (*геол.*)
**Антéй** (*мифол.*)

**Антиго́на** (*мифол.*)
**Анти́гуа һәм Барбу́да** (*дәүләт*)
**Анти́лья утраулары́**
**Антино́й** (*мифол.; тарихи шәхес*)
**Антио́хия патриа́рхи́ясе**
**анто́новка** (*алма сорты*)
**анто́новчылар** (*антоновчылык тарафдарлары*)
**анто́новчылык** (*А. С. Антонов җитәкчелегендә 1920—1921 елларда Тамбов губерниясендә булган баш күтәрү*)
**антраци́т**[1] (*ташкүмер*)
**Антраци́т**[2] (*шәһәр*)
**антропоге́н чор** (*геол.*)
**Антуа́н де Сент-Экзюпери́**
**Ану́бис** (*мифол.*)
**аони́длар** (*мифол., музалар*)
**Апана́евлар йорты́** (*Казанда*)
**Апана́й мәчете́** (*Казанда*)
**Апелле́с сызыгы́**
**Апенни́н таулары́**
**Апенни́н ярымутравы́**
**Апока́липсис**[1] (*Яңа Гаһед өлеше*)
**апока́липсис**[2] (*ахырзаман*)
**Аполло́н**[1] (*мифол.; матур ир кеше*)
**«Аполло́н»**[2] (*Америка космик корабле*)
**аполло́н**[3] (*күбәләк*)
**Аполло́н колонна́дасы** (*Павловск шәһәрендә*)
**«Аполло́н Мусаге́т»** (*неоклассик балет*)
**Аполло́ний**: **Аполло́ний әйләнәсе́**, **Аполло́ний теоре́масы**, **Аполло́ний мәсьәләсе́**
**апо́стол**[1] (*Христос укучысы; нинди дә булса идея дәвамчысы*)
**Апо́стол**[2] (*гыйбадәт китабы*)
**аппара́т**, *мәс.:* Казан шәһәре думасы аппараты, Президент аппараты, мэрия аппараты
**Аппала́ч таулары́**
**«Аппассиона́та»** (*Бетховен сонатасы*)
**аппассиона́то** (*муз.*)
**А́ппенцель** (*Швейцариядә шәһәр, кантон*)
**А́ппенцель кәҗә́ токымы́**
**А́ппий юлы́** (*Рим янында*)
**Апре́ль револю́циясе** (*Әфганстанда, 1978*)
**Араба́т теле́** (*геогр., Кырымда*)
**Араго́н** (*геогр.*)
**Араго́н иңкүлеге́**
**аракче́евчылык**
**Ара́л Буе́ далалары́**
**Ара́л диңгезе́**
**Ара́л-Ка́спий түбәнлеге́**
**Арханга́й аймагы́** (*Монголиядә*)
**Арара́т** (*Зур Арарат һәм Кече Арарат исемендәге ике тау*)
**Арара́т үзәне́**
**арбитра́ж суд**, *мәс.:* РФ Югары арбитраж суды
**Арбу́зов Бараны́** (*авыл*)

**Аргамаклы́ Сара́й** (*археол.*)
**Аргенти́на догы́** (*эт токымы*)
**Аргенти́на Респу́бликасы** (*рәсми*)
**Арго́** *һәм* **Арго́ корабы́** (*йолдызлык*)
**Аргы́ Ива́новка** (*авыл*)
**А́ргус**[1] (*мифол.*)
**а́ргус**[2] (*кош*)
**Арде́н таулары́**
**Арде́н ат токымы́**
**Аре́й** *һәм* **Аре́с** (*мифол.*)
**Аре́на ди Веро́на** (*театр*)
**Аре́с** *һәм* **Аре́й** (*мифол.*)
**Арзама́с каз токымы́**
**Ариа́дна** (*мифол.; исем*)
**Ариа́дна җебе́** (*фразеол.*)
**А́ристов йорты́** (*Казанда*)
**Арио́н** (*борынгы грек шагыйре, җырчы*)
**Ариэ́ль** (*астр.; әд. персонаж*)
**«Арка́дия» бакчасы́** (*Кабан күле буендагы ял урыны*)
**Арка́нзас-Си́ти** (*шәһәр*)
**А́рктика меду́засы** (*зоол.*)
**А́рктика түгәрәге́** (*астр.*)
**А́рктика иңкүлеге́** (*Аляскада*)
**А́рктика бассе́йны**
**А́рктика пла́тосы** (*Аляскада*)
**А́рктика һәм Анта́рктика фәнни́ тикшерену́ институты́**
**А́рктик конво́й** (*1941—1944*)
**А́рктик-Ред-Ри́вер** (*Канададагы елга*)
**Арктоге́я** (*коры җирнең зоогеографик зонасы*)
**Аркту́р** (*йолдыз*)
**Арлеки́н**[1] (*персонаж*)
**арлеки́н**[2] (*шамакай*)
**арлеки́н**[3] (*эт*)
**арлеки́н**[4] (*пәрдә төре*)
**Арлингто́н зираты́** (*Вашингтонда*)
**Армагеддо́н** (*библ.*)
**Арми́да** (*персонаж*)
**а́рмия**, *мәс.:* Кызыл армия, Совет армиясе; Беренче атлы армия
**Арре́ниус тигезләмәсе́** (*хим.*)
**Арси́** (*Эфиопия регионы*)
**Арси́-Бале́ кәҗә́ токымы́**
**артезиа́н суы́**
**Артеми́да** (*мифол.*)
**ару́ җые́н** (*керәшеннәрдә: «православие динендәге христиан дөньясы» мәгъ.*), *мәс.:* 30 сентябрьдә ару җыен изге Софиянең Вера, Надежда, Любовь атлы өч кызын искә ала
**арха́нгел**[1] (*хрс., олуг фәрештә*), *мәс.:* архангел Михаил
**Арха́нгел**[2] (*храм атамаларында*), *мәс.:* Архангел Гавриил храмы (*Мәскәүдә*), Архангел Михаил чаң манарасы (*Казанда*)
**Арха́нгел бистәсе́**[1] (*Казанда*)
**Арха́нгел Бистәсе́**[2] (*авыл*)
**Арха́нгел Михаи́л чаң манарасы́** (*Казанда*)
**Арха́нгел соборы́** (*Мәскәүдә*)
**Арха́нгел зираты́** (*Казанда*)
**архе́й** *һәм* **археозо́й** (*геол.*)
**Архиере́й да́часы** (*Казанда*)

**Архиме́д**: **Архиме́д аксио́масы**, **Архиме́д законы́**, **Архиме́д җисемнәре́**, **Архиме́д спирале́**
**архипела́г** (*геогр.*), *мәс.:* Көнбатыш Эстония архипелагы
**Арча́** (*шәһәр һәм район*)
**Арча́ даругасы́** (*тар.*)
**Арча́ зираты́** (*Казанда*)
**Арча́ педаго́гика көллияте́**
**арысла́н**[1] (*хайван*)
**Арысла́н**[2] (*йолдызлык һәм зодиак билгесе; шул йолдызлык астында туган кеше*)
**Арысла́н Гәрә́й** (*Кырым ханы*)
**Арысла́н Ге́нрих** (*Генрих III тур.*)
**Арысла́н Йөрәге́** (*астр., Арыслан йолдызлыгының α сы*)
**Арысла́н Йөрә́к Ри́чард**
**Асбе́ст таулары́** (*Африкада*)
**А́сия** (*астероид*)
**Аска́ния-Но́ва** (*Херсондагы саклаулык*)
**Асклепий** (*мифол.*)
**Асмоде́й** (*библ.*)
**Аспе́ргер синдромы́**
**ассамбле́я**[1] (*оешма*), *мәс.:* Татарстан халыклары ассамблеясы, Төньяк Атлантика ассамблеясы, Евро́па парламентара ассамблеясы
**Ассамбле́я**[2] (*рәсми, БМО*)
**ассоциа́ция** (*оешма, берләшмә исемнәрендә*), *мәс.:* Бөтендөнья теннис ассоциациясе, Һава транспорты халыкара ассоциациясе, Азия һәм Африка илләре язучылары ассоциациясе
**Аста́рта** (*грекларда мәхәббәт һәм хакимлек алиһәсе*)
**Астронавтла́р Култыгы́** (*Айда*)
**ат**[1] (*хайван*)
**Ат**[2]: **Ат елы́** (*Көнчыгыш календаре буенча унике еллык циклның җиденче елы*); **Ат** (*шул елда туган кеше*)
**Атака́ма** (*чүл*)
**Атаба́й-Әнкәбә́** (*авыл*)
**Атаба́й торулыгы́** (*археол.*)
**Ататөре́к Мостафа́ Кәма́ль** (*төрек дәүләт эшлеклесе*)
**Ат Башы́** (*томанлык*)
**а́тказанган арти́ст** (*исем*)
**а́тказанган укытучы́** (*исем*)
**а́тказанган фән эшлеклесе́** (*исем*)
**Атланти́да** (*мифик утраудәүләт*)
**Атла́нтика** (*геогр.*)
**Атла́нтик океа́н**
**атла́с**[1] (*тукыма*)
**Атла́с**[2] (*авыл*)
**Атла́с**[3] (*астр.*)
**а́тлас**[4] (*ыру атамаларында һәм конкрет басмалар исемнәрендә*), *мәс.:* дөнья атласы, автомобиль юллары атласы, Урта Идел һәм Урал Буе татар халкы сөйләшләре атласы
**Атла́с таулары́** (*геогр.*)

**Атти́ла** (*һуннар башлыгы*)
**А́уди**[1] (*концерн*)
**«а́уди»**[2] (*автомобиль*)
**«Ау́м Синрикё»** (*дини секта*)
**Аустерли́ц сугышы́** (*1805*)
**Ау́н Сан** (*Бирма сәясәтчесе*)
**Ау́н Сан Су Чжи** (*Мьянма сәясәтчесе*)
**Аучы́ Мәхмә́д** (*Мәхмәд IV тур.*)
**А́у Этләре́** *һәм* **Бурза́й Этлә́р** (*йолдызлык*)
**Афа́р** (*иңкүлек*)
**Афа́р кәҗә́ токымы́**
**Афи́на** (*мифол.; шәһәр*)
**Афи́на дәүләте́** (*тар.*)
**Афи́на консерватóриясе**
**Афи́на Палла́да** (*мифол.*)
**Афóн** (*тау*)
**Афóн монастыре́**
**А́фрика** (*материк*); А́фрика чумасы́ (*вет.*); А́фрика ака́ралары, А́фрика тәвә́ кошы́ (*зоол.*)
**А́фрика-Анта́рктика казанлыгы́** (*Атлантик океанда*)
**а́фрикалы**
**А́фрика пигмее́** (*кәҗә токымы*)
**А́фрика платфóрмасы** (*геол.*)
**А́фрика уеннары́** (*Африка континенты атлетлары ярышы*)
**Афроди́та** (*мифол.; гүзәл хатын-кыз тур.*)
**Афроди́та Җире́** (*астр., Венера планетасында*)
**Ахалтәкә́** (*оазиз*)
**ахалтәкә́** (*ат токымы*); *ләкин:* **Ахалтакә аты**
**ахаше́ни** (*шәраб*)
**Ахе́я берлеге́** (*Борынгы Грециядә*)
**Ахерóнт** (*мифол.*)
**Ахи́лл** *һәм* **Ахилле́с** (*мифол.*)
**Ахилле́с**[1] *һәм* **Ахи́лл** (*мифол.*)
**Ахилле́с**[2] (*астероид*)
**Ахилле́с үкчәсе́** (*фразеол.*)
**Ахи́лл рефле́ксы** (*мед.*)
**Ахи́лл сеңере́** (*мед.*)
**Ахи́лл Та́тий** (*борынгы грек язучысы*)
**Ахимәнилә́р** (*династия*)
**ахша́м**; ахша́м вакыты́, ахшам намазы, ахшам азаны
**ахырзаман** (*Кыямәт көне алды чоры, заман ахыры, апокалипсис*); ахырзаман пәйгамбәре, ахырзаман галәмәтләре
**Аһагга́р таулыгы́** (*геогр.*)
**Аһурама́зда** (*иран мифологиясендә: иң олуг илаһ*)
**Аци́с һәм Галате́я** (*мифол.*)
**Ач дала́** (*геогр.*)
**Аш-Буҗи́** (*авыл*)
**Ашхаба́д фетнәсе́** (*1918*)
**Ашы́т** (*елга*)
**аэропóрт**, *мәс.:* Внуково аэропорты, Шереметьево аэропорты, Габдулла Тукай исемендәге Казан аэропорты
**АЭС** (*кыск.:* атом электр станциясе)
**Аю́ А́льбрехт** (*Бранденбург графы*)

**Аюдаг** (*Кырымдагы тау*)
**Аю Көйдергә́н** (*авыл*)
**Ая́з Гыйлә́җев исемендәге́ Чаллы́ тата́р дәүлә́т дра́ма теа́тры**
**Ая́кс** (*мифол.*): ике́ Ая́кс
**аятулла́** (*шигыйларда титул*), *мәс.:* аятулла Хамәни, аятулла Хумәйни, бөек аятулла

# Ә

**Әби́ патша́** *һәм* **Бөе́к Екатери́на** (*Екатерина II тур.*)
**Әбү-Да́би** (*шәһәр һәм әмирлек*)
**Әбү́**: **Әбү́ Хәнифә́**, **Гали́ ибн Әбү́ Тали́б**
**Әбү́ әл-Галә́ әл-Мәгарри́** (*гарәп шагыйре һәм фикер иясе*)
**Әбү́ әл-Хәсә́н Гали́ бин Исмәгы́йль әл-Әшгари́** (*илаһиятчы*)
**Әбү́ Бәке́р** (*хәлифә*)
**Әбү́ Габдулла́һ Мөхәммә́д бин Исмәгы́йль әл-Бохари́**
**Әбү́ Гали́ ибн Сина́** *һәм* **Әбү́ Гали́ Хөсәе́н ибн Габдулла́һ ибн әл-Хәсә́н ибн Гали́ ибн Сина́** *һәм* **Ибн Сина**
**Әбүгалисина́** (*персонаж*)
**Әбү́ Җәһе́л** (*Әбү Хәким бин Һишамның кушаматы*)
**Әбүзә́р мәчете́** (*Яр Чаллыда*)
**Әбү́ Муса́ әл-Әшгари́**
**Әбү́ Рәйха́н Мөхәммә́т бин Әхмә́д әл-Бируни́** *һәм* **Әбү́ Рәйха́н әл-Бируни́**
**Әбү́ Хәми́д әл-Гарнаты́й**
**Әбү́ Хәми́д әл-Газзали́** *һәм* **има́м Газзали́**
**Әбү́ Хәнифә́** (*мәзһәб имамы*)
**Әгерҗе́** (*шәһәр, авыл һәм район*)
**«Әгълә́» («Иң югары») сүрәсе́**
**«Әгъра́ф» («Киртәлә́р») сүрәсе́**
**Әди́рнә солыхы́** (*1829*)
**Әдрә́н диңге́з**
**әҗә́л**[1] (*үлем*)
**Әҗә́л**[2] (*персонаж*)
**Әҗә́л Күле́** *һәм* **Үле́м Күле́** (*Айда*)
**Әҗе́м мәчете́** (*Казанда*)
**Әҗмә́р ко́мплексы** (*археол.*)
**Әҗмә́т каберлеге́** (*археол.*)
**Әйгәли́ баты́р** (*персонаж*)
**Әки́ Аланы́** (*авыл*)
**«Әкия́т» тата́р дәүлә́т курча́к теа́тры**
**Әкрә́м авылы́ кузгалышы́** (*1842*)
**әл-Әзһә́р** (*Каһирәдәге университет*)
**әл-Әшгари Әбү́ әл-Хәсә́н Гали́ бине́ Исмәгы́йль** (*илаһиятчы*)

**Әлбәдә́н** (*авыл*)
**әл-Болгари́** (*Болгарга бәйлелекне белдергән нисбә*): **Хуҗа́ Әхмә́т әл-Болгари́, Таҗетди́н әл-Болгари́, Мәхму́д әл-Болгари́, Хәми́д бин Идри́с әл-Болгари́**
**әл-Бируни́** *һәм* **Бируни́** (*Урта Азия галиме*)
**әл-Газзали́ Әбу́ Хәми́д** (*илаһиятчы*)
**«әл-Га́ләме әл-ислами́»** (*газета*)
**әл-Гарнатый Әбу́ Хәми́д**
**«әл-Гаср әл-җәди́д»** *һәм* **«Әлгасрелҗәди́д»** (*журнал*)
**Әлдерме́ш** (*авыл*)
**«Әлдермештә́н Әлмәндә́р»** (*Т. Миңнуллин пьесасы*)
**Әлҗәзаи́р** *яки* **Җәзаи́р** (*Алжир*)
**«әл-Исла́х»** *һәм* **«Әлисла́х»** (*газета*)
**Әлки́** (*авыл, район*)
**әл-Мавәрди́ Әбу́ әл-Хәсә́н Гали́ бине́ Мөхәммә́д**
**әл-Мәрҗани́ мәчете́** *һәм* **Мәрҗани́ мәчете́**
**Әлмә́т** (*авыл, шәһәр, район*)
**Әлмә́т-Бөгелмә́ сәнәга́ть төйнәлеше́**
**Әлмә́т дәүлә́т нефть институты́**
**Әлмә́т машинала́р төзу́ заводы́**
**Әлмә́т му́зыка учи́лищесы**
**Әлмә́т насосла́р заводы́ (Әлна́с)**
**Әлмә́т полите́хника те́хникумы**
**Әлмә́т тата́р дәүлә́т дра́ма теа́тры**
**Әлна́с** (*кыск.:* Әлмәт насослар заводы)
**Әлхәмра́** (*Гранада шәһәрендәге әмир сарае*)
**Әмә́т** (*посёлок*)
**«Әмә́т» ста́нциясе**
**Әнвә́р паша́**[1] (*госманлы хәрбие*)
**Әнвә́р Паша́**[2] (*бенгаль язучысы*)
**«Әнбия́» («Пәйгамбәрлә́р») сүрәсе́**
**«Әнга́м» («Терле́к») сүрәсе́**
**Әндәлу́с** (*Испаниядә*)
**Әндәлу́с ак кәҗә́ токымы́**
**Әндәлу́с таулары́**
**Әндәлу́с түбәнлеге́**
**Әндри́ казнасы́** (*фразеол.*)
**«Әнилә́р» мәчете́** (*Казан, Чистай шәһәрләрендә*)
**«Әнфа́ль» («Табышла́р») сүрәсе́**
**Әсә́н Елга́** (*авыл*)
**Әсә́н Елга́ мәчете́** (*Кукмара районында*)
**әрмән**[1] (*этноним*), *мәс.:* әрмән теле
**Әрмән**[2](*Әрмәнстан мәгъ*), *мәс.:* Әрмән таулыгы, Әрмән төклетурасы
**Әрмә́н апо́стол чиркәве́**
**Әрмә́н бистәсе́** (*тар.*)
**Әрмә́н вулка́н таулыгы́** (*геогр.*)
**Әрмәнста́н** (*дәүләт*)

**Әрмә́н таулыгы́** (*геогр.*)
**Әр-Рия́д**
**Әстерха́н во́бласы**
**Әстерха́н өлкәсе́**
**әстерха́н сөйләше́**
**Әстерха́н тата́р дра́ма теа́тры**
**Әстерха́н татары́**
**Әстерха́н ханлыгы́** (*тар.*)
**әстерха́н чикләвеге́**
**әс-Саксини́ Сөләйма́н бин Дау́д**
**әсха́бе кәһф**
**әттәхия́т** (*дога*)
**Әти́л** (*иск. Идел*)
**Әтнә́** (*авыл, район*)
**Әтнә́ тата́р дәүлә́т дра́ма теа́тры**
**Әтрә́ч ко́мплексы** (*археол.*)
